• МӘХӘЛЛӘ •

БАЛАЛАР САБАН ТУЕНА РӘХИМ ИТЕГЕЗ!

*3 бит*

• СОРАУ-ҖАВАП •

ЗӘКЯТ ТАПШЫРУ КАГЫЙДӘЛӘРЕ

*7 бит*

• ТӘРБИЯ •

МӘЧЕТ ҺӘМ БАЛАЛАР

*12 бит*

• БУ КЫЗЫКЛЫ •

СӘЛАМӘТЛЕК ЭЛИКСИРЫ

*15 бит*

*№ 6 (287)* *Татарстан мөселманнары диния нәзарәте басмасы* *шәүвәл 1440*

*Июнь, 2019*

دين و معيشت

ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ

# Изге Болгар җыены – 2019









Болгар дәүләт тарих-архитектура музей-тыюлыгы территориясендә «Изге Болгар җыены»нда Россиянең төрле төбәкләреннән күпсанлы мөселманнар катнашты

*Дәвамы 8 нче биттә*

Газетада Аллаһы Тәгаләнең исемнәре, Коръән аятьләре булганлыктан, басмага игътибарлы булыгыз!

12+

# «Россия – Ислам дөньясы» стратегик караш төркеме утырышында «Хозур» нәшрият йорты эшчәнлеге билгеләп үтелде

Шәүвәл аеның 16 нчы көнендә Татарстан мөселманнары башлыгы Камил хәзрәт Сәмигуллин «Россия – Ислам дөньясы» стратегик караш төркеме утырышы эшендә катнашу өчен Мәскәүгә эшлекле сәфәр кылды. Утырыш Россия чит ил эшләре министрлыгының Зур йортында презентация рәвешендә узды – киңәшмәдә катнашучыларга «Россия – Ислам дөньясы» стратегик караш төркеме эшчәнлеген, аерым алганда, Төркемнең яңа эш ысуллары һәм механизмнарын, аның төп юнәлешләрен тәкъдим иттеләр. Чараның спикерлары сыйфатында Россия Федерациясе Чит илләр эшләре министры Сергей Викторович Лавров, Татарстан Республикасы Президенты, «Россия – Ислам дөньясы» стратегик караш төркеменең рәисе Рөстәм Нургалиевич Миңнеханов һәм аның Төркемдәге урынбасары Фәрит Мөбәрәкшә улы Мөхәммәтшин булды.

Республика башлыгы искәрткәнчә, бүген дөньяда мөселманнар саны 1,7 млрд кеше тәшкил итә һәм үсә бара. Россиянең мөселман халкы да арта.

«Сәяси, икътисади, мәдәни һәм мәгариф өлкәләрендә ислам дәүләтләре белән хезмәттәшлекнең күптәнге традициясе бар. Россия Президенты Владимир Путин мөселман илләре белән хезмәттәшлеккә зур игътибар бирә», – дип билгеләп үтте Р. Миңнеханов.

Россия дәүләт эшлеклесе Евгений Примаков һәм Татарстанның беренче Президенты Минтимер Шәймиев тарафыннан 2006 елда булдырылган «Россия – Ислам дөньясы» стратегик караш төркеме турында сүз йөрткәндә, Рөстәм Миңнеханов аның эшчәнлегенең зур ихтыяҗга ия булуын ассызыклап узды.

ТР Президенты сүзләренә караганда, «Россия – Ислам дөньясы» стратегик караш төркеме кысаларында хезмәттәшлек итүнең перспектив юнәлешләре булып бүген хәләл банкинг һәм хәләл продукция җитештерү, шулай ук хәләл яшәү рәвешен үстерү тора.

«Хәзер бу перспективалы һәм киңкырлы юнәлеш. Мөселманнарның ихтыяҗлары – бизнес өчен яхшы мөмкинлекләр. Ислам динен тотучы төбәкләрдә генә түгел, әлеге стандартлар буенча эшли ала торган төбәкләрдә дә», – дип ассызыклады Рөстәм Миңнеханов.

Фәрит Мөхәммәтшин докладында ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең «Хозур» нәшрият йорты эшчәнлеген уңай яктан билгеләп үтте. Нәшрият йорты «Россия – Ислам дөньясы» стратегик караш төркеменең Россия һәм Ислам дөньясы илләренең үзара мәгълүматлылыгын арттыру эшен гамәлгә ашыруга актив рәвештә җәлеп ителә.




Эшлекле очрашуда Ислам Хезмәттәшлеге Оешмасы илләре илчеләре, «Россия – Ислам дөньясы» стратегик караш төркеменең гамәлдәге әгъзалары, Россия Федерациясе Президенты Администрациясе, Россия Федерациясе Федераль җыены, Татарстан Республикасы вәкилләре һәм РФ субъектлары башлыклары, җәмәгать һәм дин эшлеклеләре катнашты.

Россия Федерациясенең мөселман илләре белән мөнәсәбәтләрен мәдәниара һәм цивилизацияара кораллар ярдәмендә үстерү максатыннан 2006 елда Евгений Максимович Примаков һәм Минтимер Шәрипович Шәймиев җитәкчелегендә «Россия – Ислам дөньясы» стратегик караш төркеме булдырылды. 2014 елда Россия Федерациясе Президенты Владимир Владимирович Путин рәислек вазифасын Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Нургалиевич Миңнехановка йөкләде. Бүгенге көндә Төркемгә 27 мөселман иленнән 33 күренекле дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе, шул исәптән чит ил эшләре буенча элеккеге министрлар һәм премьер-министрлар, шулай ук Ислам Көнчыгышының танылган дин галимнәре керә.

■ **dumrt.ru**

# «Даруль-ифта» үзәгендә бер ай эчендә 300 дән артык мөрәҗәгать эшкәртелгән

Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтендә Рамазан аеның беренче көнендә рәсми рәвештә эшли башлаган һәм бүген дә үз эшен дәвам иткән «Даруль-ифта» call-үзәге эшчәнлегенә беренчел нәтиҗәләр ясалды. Тәүге аен сынаулы рәвештә эшләгән call-үзәк әлеге хезмәтнең халык арасында югары ихтыяҗга ия булырга мөмкинлеген күрсәтте. Барлыгы бер ай эчендә нәзарәтнең шәригать белгечләре call-үзәк аша Россиянең төрле почмакларыннан – Татарстан, Башкортстан республикаларыннан, Чиләбе, Омск, Оренбург өлкәләреннән, Мәскәүдән һ.б. төбәкләрдән килеп ирешкән 300 дән артык мөрәҗәгатьне эшкәртте.

Республика мөфтиятенең «Даруль-ифта» call-үзәге илдә шалтыратулар эшкәртү буенча бушлай федераль номерлы бердәнбер мөселман үзәге булып кала бирә.

Күп каналлы телефон линиясенә кабул ителгән мөрәҗәгатьләр статистикасына караганда, сорауларның күпчелеге дини характерга ия. Әйтик, Рамазан аенда мөселманнарны ураза тоту, фитыр, фидия садакаларын, зәкят түләүгә бәйле сораулар аеруча кызыксындырса, бүген халык өчен намаз, талак, Кыямәт көне, шәүвәл ае уразасы, гаурәтне каплау, риэлтор эшчәнлегенең рөхсәт ителүителмәве, теге яки бу дини йоланы башкару тәртибе һәм башка бик күп мәсьәләләр актуаль булып тора. Моннан тыш, call-үзәккә белешмә мәгълүмат алу өчен дә мөрәҗәгать итәләр. Шунысы игътибарга лаек: барлык мөрәҗәгатьләрнең 60 проценты ир-атларга туры килә. Телефон консультациясенең уртача озынлыгы 2-3 минутны тәшкил итә.

Искәртеп үтик: «Даруль-ифта» – шәригатьнең теге яки бу мәсьәләләре буенча фәтвалар чыгару өчен ТР МДН тарафыннан махсус булдырылган күпканаллы call-үзәк. Теләге булган һәркем эш көннәрендә сәгать **10.00нан 16.00га кадәр 8 800 222 7667** номерына шалтыратып, үзен борчыган сорауларга җавап алырга мөмкин.

Халык белән тыгыз элемтәдә торуга Татарстан мөфтиятендә өстенлекле игътибар бирелә. Нәзарәткә төрле сораулар белән читтән торып мөрәҗәгать итү өчен берничә мөмкинлек булдырылган. Мисал өчен, 2018 елда Рамазанның беренче көннәреннән үк Татарстан Республикасы мөфтиенең «Дини сорау» консультатив интернет-линиясе үз эшен башлап җибәрде – мөселманнар



шәригать буенча кызыксындырган сораулар белән махсус булдырылган e-mail: dini.sorau@tatar.ru аша Камил хәзрәт Сәмигуллинга шәхсән мөрәҗәгать итә ала. Аңа ТР мөселманнары Диния нәзарәте рәсми сайтының махсус «Мөфтигә сорау» сәхифәсе аша да сораулар җибәрергә була. Ислам тематикасына кагылышлы сорауларга җавапларны ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең Ышаныч телефонына шалтыратып та алырга мөмкин: +7 939 50 50 700.

■ **dumrt.ru**

# Татарстан мөфтие I дәрәҗәдәге «Җәмгыять алдындагы казанышлары өчен» медале белән бүләкләнде



Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин I дәрәҗәдәге «Җәмгыять алдындагы казанышлары өчен» медале белән бүләкләнде. Республика мөселманнары башлыгына бүләкне республиканың җәмәгать эшлекләре, патриотик, яшьләр һәм ветераннар оешмалары һәм спорт федерацияләре җитәкчеләре карары белән ТР Җәмәгать эшлекләре берлеге президиумы рәисе Александр Даренков тапшырды. Ул мөфти хәзрәтне лаеклы бүләге белән тәбрикләп, аның Татарстанда динара багланышларны, традицион рухи кыйммәтләрне һәм республиканың спорт имиджын ныгытуга керткән өлешен билгеләп үтте. «ТР Җәмәгать эшлекләре президиумы әгъзалары – алар арасында Советлар Союзы һәм Россия геройлары, Хезмәт геройлары, спорт федерацияләре һәм берлекләре президентлары – Сезнең җәмгыятьне берләштерү, яшь буынга рухи-әхлакый, патриотик һәм спорт тәрбиясе бирү юнәлешендәге хезмәтегезне югары бәяли», – дип мөрәҗәгать итте Александр Александрович хәзрәткә медаль тапшырганда.

Камил хәзрәт Сәмигуллин 2013 елдан бирле Татарстан мөфтие булып тора, 2017 елда бертавыштан ТР мөселманнары Диния нәзарәте башлыгы итеп кабаттан сайланды. Ул эшләгән чорда мөфтият эшчәнлегенең өстенлекле юнәлешләре буларак ислам мәгариф системасын үстерү, Коръәнне өйрәнү, хафизларны әзерләү мәктәбен, татар дини-рухи мирасын торгызу, татар милли үзенчәлекләрен саклау, яшьләргә рухи-әхлакый һәм патриотик тәрбия бирү, «татар зыялысы» катламын тәрбияләү, халыкара мөнәсәбәтләрне үстерү, халыкны дини яктан тәрбияләү һәм нәшрият эшчәнлеге билгеләнде.

■ **dumrt.ru**

# Республика мөселман балалар Сабан туена рәхим итегез!

2019 елның 14 июлендә Балтач районы Бөрбаш авылында уникенче тапкыр Республика мөселман балалар Сабан туе узачак. Әлеге традицион чара Татарстанның баш казые, Балтач районы имам-мөхтәсибе Җәлил хәзрәт Фазлыев тырышлыгы белән оештырыла. Балалар өчен дип аталса да, бәйрәмне күрергә теләп, республика хөкүмәте вәкилләре, дин әһелләре, күренекле шәхесләр, шулай ук Россиянең төрле төбәкләреннән күп санлы кунаклар килә.

Сабан туе балаларның Коръән һәм догалар укуы, мөнәҗәт әйтүе, шигырь сөйләве белән үрелеп барачак. Бәйрәм кысаларында сабыйлар өчен төрле уеннар, ярышлар, нәниләрне рухи-әхлакый тәрбия бирүгә юнәлтелгән чаралар оештыру каралган. Кул көрәше, капчык белән сугышу, капчык киеп йөгерү, көянтә-чиләк белән су ташу, тәңкә җыю, чүлмәк вату, таяк тартышу, әтәч тоту, туры баганага менү, утын кисү, йөгерү, әйбер кисү кебек уеннар булачак.

Мөселман балалар Сабан туйлары шулай ук 28 июньдә Кайбыч һәм Югары Ослан районнарында, 4 августта Мамадышта узачак.

■ **dumrt.ru**



## Игълан! Сатучы һәм редактор таләп ителә!

- **«Хозур» нәшрият йортының китап кибетенә сатучы таләп ителә. Сату өлкәсендә эш тәҗрибәсе булу хуплана. Тулырак мәгълүмат: 253-86-33.**
- **«Хозур» нәшрият йортына рус телендәге китапларны тикшерүче (корректор) таләп ителә. Таләпләр: югары филологик белем, дин нигезләрен белү. Белешмәләр өчен телефон: 598-09-42.**

# Өйгә керү һәм чыгу кагыйдәләре



## Өйгә кергәндә

Нинди дә булса бинага кергәндә уң аяктан керегез, бу Пәйгамбәребез галәйһиссәламнең сөннәте булып тора. Өйгә кергәндә яки чыкканда ишекне типмәгез, этмәгез һәм шакылдатып япмагыз. Аны нык тавыш белән (шакылдап) ябылырлык хәлдә дә калдырмагыз. Мөхәммәд пәйгамбәр мөселманнарга һәр мәсьәләдә йомшаклык белән эш итәргә васыять итте.

Кемгәдер кунакка килгәч тә, ишеккә нык итеп шакырга кирәкми. Сез шакып та, ишекне ачмыйлар икән, хуҗаларның хәзерге вакытта эшләре бардыр, дип уйлап, кайтып китәргә кирәк. Пәйгамбәребез галәйһиссәлам: «Әгәр сез өч тапкыр (керергә) рөхсәт сорап, җавап алмасагыз, китегез», – дип әйткән.

Әгәр сез кайткан вакытта өйдә кемнеңдер йоклавын белсәгез, анда әкрен генә кереп, башкаларга уңайсызлыклар тудырмагыз, тавыш чыгармагыз. Бер хәдистә: «Без Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм өчен аның сөт өлешен саклый идек. Төнлә кайткач ул безне йоклаучылар ишетерлек, әмма йоклаганнарны уятмаслык тавыш белән сәламли иде», – диелгән. Шулай ук төнге намазларны укыганда да, Расүлебез йокламаучылар ишетерлек, йоклаучылар уянмаслык итеп укыган.

## Сәламләү, дога кылу

Өйгә кергәндә һәм чыкканда сәлам бирми калмагыз. Әлбәттә, динебездә иң күркәм сәламләү булып «әссәламү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәракәтүһү» сүзләре тора. Аны башка сүзләргә алыштырырга кирәкми, чөнки бу Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең сөннәте булып тора. Пәйгамбәребез гаилә әһелләрен башка кешеләргә караганда сәламләүгә күбрәк лаек кешеләр дип атаган. Хәтта өйдә кеше булмаса да, кергәндә сәлам бирергә кирәк.

Шулай ук кергәндә «бисмилләһиррахмәнир-рахим» сүзләрен әйтү дә сөннәт булып тора. Өйдән чыкканда мондый дога әйтелә: «Бисмилләһ, тәвәккәлтү галәллаһ. Лә хәүлә вә лә куввәтә иллә билләһ». Мәгънәсе: «Аллаһы исеме белән, Аллаһыга тәвәккәл кылам. Аллаһыдан башка көч вә куәт юк».

## Рөхсәт сорау

Өйдәгеләргә үзегезнең кайтуыгызны сиздерегез, кайтуыгызны әйтегез. Беркайчан да аралашуны кычкыру һәм бәхәсләрдән башламагыз. Гаилә әһелләрегез янына кисәк кенә килеп, аларны куркытмагыз.

Гаилә әһелләрегез үз бүлмәләрендә ял итә икән, алар янына керергә теләсәгез, башта рөхсәт сорагыз, ишеккә шакыгыз. Аларга уңайсызлык тудырмагыз, тынычлыкларын бозмагыз. Бервакыт Пәйгамбәребез галәйһиссәламнән: «Әниебезнең бүлмәсенә керер өчен рөхсәт сорарга кирәкме?» – дип сораганнар. Ул әйе дип җавап биргән. Сорау бирүче: «Без бер өйдә яшибез», – дип әйткән. Расүлуллаһ: «Анаң янына керер өчен рөхсәт сора», – дип әйткән. Кеше: «Мин бит аны карыйм», – дип килешмәвен белдергән. Пәйгамбәребез: «Рөхсәт сора. Син аны киенмәгән кыяфәттә күрергә телисеңме?» – дип җавап кайтарган. Сораучы: «Юк!» – дигән. Пәйгамбәр галәйһиссәлам: «Алайса кергәндә рөхсәт сора», – дип әйткән.

■ Islam-today

# Пәйгамбәребез галәйһиссәлам иске киемнәрен нишләткән?

Кием-салым Аллаһы Тәгалә биргән зур нигъмәт булып тора, һәм кешеләрдән башка ул бүтән җан ияләренә бирелмәгән.

Раббыбыз бу нигъмәте хакында Изге китабыбыз Коръәндә болай дип әйтә:

**«Ий Адәм балалары! Без сезгә киемнәр яраттык, ул киемнәр гаурәтләрегезне каплар, янә мал яраттык һәм дә тәкъвалык киемен бирдек, ул тәкъвалык – саклану киеме хәерледер, ошбу зекер ителгән нәрсәләр Аллаһы Тәгаләнең галәмәтләре, шаять, кешеләр вәгазьләнерләр».**

«Әгъраф / Пәрдә», 7:26

Пәйгамбәребез галәйһиссәлам аны башкалардан аерып тормый торган гади киемнәр кигән. Сөннәттән аның мондый төр киемнәр киюе билгеле: чалма, озын күлмәк, алды ачык озын күлмәк сыман кием, чапанга охшаган өске кием.

Яңа кием кигәндә Мөхәммәд пәйгамбәр: «Йә Аллаһым! Син мине шушы киемгә (күлмәккә, чалмага) киендердең. Синнән аның хәерле булуын һәм ясалу максатының да хәерле булуын сорыйм. Аның золымыннан вә аның (киемнең) ясалу максатының золымыннан Сиңа сыенам», – дип әйтә торган булган.

Бүгенге көндә без киемне бик еш алыштырабыз, иске киемнәребез еллар буе киштәләрдә ятарга да мөмкин. Ә Пәйгамбәребез нәрсә киңәш иткән соң? Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең яңа киеме барлыкка килсә, искеләрен ул мохтаҗларга бирә торган булган һәм: «Яңа кием алгач, дога кылып, искесен мохтаҗ мөселманга бирүчене (гомере дәвамында һәм үлеменнән соң), биргән киеменең берсе генә булса да мохтаҗның өстендә булганчыга кадәр, Аллаһы Тәгалә саклар», – дип әйткән. Ә әгәр сез биргән киемнәрдә намаз укысалар, башка изге гамәлләр кылсалар, сезгә савабы тагы да артып кайтарылыр, ин шә Аллаһ.

■ Islam-Today

# Балалар әти-әниләре белән бер урында йоклый аламы?



Әлеге сорауга мөселман галимнәре мондый җавап биргән: «Ун яшь тулуга, балалар әтиәниләреннән һәм абый-эне, апасеңелләреннән аерым йокларга тиеш. Малайларга малайлар белән һәм кызларга кызлар белән дә йокларга катгый тыела» («Фәтәва Нәвәви», 215 б).

Ә хәзерге педагог һәм психологлар инде бер яшьтән башлап балалар әти-әниләреннән аерым йокларга тиеш дигән фикердә.

Әмма, сөннәттә билгеләнгән чикләр һәм кагыйдәләр, һичшиксез, хатасыз һәм иң хәерле булып торалар. Шуңа күрә, балалар ун яшькә җиткәч, әти-әниләреннән аерым, үзләре генә, үз урыннарында йокларга тиешләр. Алда әйтеп үтелгәнчә, малайларның малайлар белән, кызларның кызлар белән йоклавы да тыела.

■ Islam-Today

# Ураза бәйрәмендә



Быел Казанның М. Горький исемендәге үзәк мәдәният һәм ял паркында шәһәркүләм ураза бәйрәме уздырылды. Паркка керү юлында ук, «Рамазан Фест: бергә булыйк!» дип зур итеп язып куелган баннер-афишада бәйрәмнең программасына кадәр күрсәтелгән. Татарстан мөселманнары диния нәзарәте белән Вахитов һәм Идел буе районнары мөхтәсибәте берлектә оештырган бәйрәмнең үзәге – парк уртасында чирәмле алан булып, анда көйләнгән сәхнә тирәсен халык сарып алган иде. Бәйрәм башланырга бер-ике сәгать алдан килеп, шул аланлыкта табын корып утыручылар арасында яшь гаиләләрнең күплеге күзгә ташланды.

Вакыт иртәрәк булса да, сәхнә янында инде алып баручы Айрат Заһриев һәм тамаша оештыручылар кайнаша. Айрат белән бергәләп бәйрәмне алып барачак малайның дулкынлануы йөзенә үк чыккан. Татарча эндәшүемә, янәшәсендәге яшь ханым җавап биреп өлгерде. Татар дигәнем урыс малае Аркадий Кузнецов икән. Унбер яшьлек Аркадийның мөселман бәйрәмен әле беренче генә алып баруы. Гаҗәпләнүемә каршы, аның әнисе Евгения улының бу бәйрәмне алып барачагына шатлануы, үзләре православие динендә булсалар да, мөслимәләр арасыннан дус кызлары күплеге турында сөйләп торды. Алга китү булса да, Аркадийның сәхнәдә үзен иркен тотуын, Айрат абыйсыннан һич тә калышмавын да әйтим.

Сәхнәдәге бәйрәм тугыз яшьлек Алим Алиуллинның Коръәннән «Әгълә» сүрәсен яттан укуы белән башланып китте. Икенче классны гына тәмамлаган Алим Аллаһының бөеклеген, Аның бар нәрсәне юктан бар кылуын, коры җиргә тереклек бирүен, яшел үләннәрне үстерүен сурәтләгән аятьләрне яттан сөйләгәндә, әнисе Гүзәл улы өчен борчылып басып торды, ә тамаша кылучылар йөзендә соклану чагылды.

Бар игътибары сәхнәдә булган тамашачы, мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллинның бәйрәм котлавын да күңеленә сеңдереп утыргандыр. Камил хәзрәтнең, хәдискә таянып, бу дөньяда өч нәрсәдән – Коръән укудан, Аллаһыны искә алудан һәм үз динеңдәге кешеләр белән аралашудан кала, чын канәгатьлек бирә торган башка бернәрсә дә юк, дигән фикерен дә истә калдыргannардыр. Шулай ук, Вахитов һәм Идел буе районнары мөхтәсибе Йосыф хәзрәт Дәүләтшинның да бәйрәм белән тәбрикләвен; нинди генә авыр заманнарда да әби-бабайларның динебезне, гореф-гадәтләребезне саклап калуларын искә төшерүен; бүгенге көн мөселманнары өчен дин тотуда барлык мөмкинлекләр тудырылганын искәртүен һәм «бәйрәмнәрдә дә, эштә дә, гаиләләрдә дә бергә булыйк» дип, туганнарча мөнәсәбәтне сакларга чакыруын тамаша кылучылар үз хәтерләренә салып куйганнардыр.

Сәхнәдә төрле кызыклы конкурслар шоу-тамашалар белән аралашып барды. «Минбәр» татар-дини театры җитәкчесе Ильяс Халиковның мөнәҗәтләр көйләвен дә тамашачы яратып тыңлады.

Кызыклы уеннар яратучы балалар һәм олылар өчен, аланлыкның икенче башында «Ладошки» уены оештырылган иде. Катнашучылар кабартылган резин кул эченә кереп, уенны алып баручы әйткән санга егылырга тиешләр. Монда, әлбәттә, җитезлек тә, игътибарлылык та кирәк. Паркның футбол мәйданчыгы да буш түгел: әтиле-уллы ике гаилә кабартылган иләмсез зур резин кәшәкә ярдәмендә, шундый ук зур «алка»га тигезеп, каршы як капкага кертергә тиешләр. Монда да кызык карарга яратучылар җыелган, арада көч биреп торучылары да бар.

Фонтан янында – бала-чага. Кыз балаларның йөзләрен төсле буяу белән бизиләр. Аквагрим осталарының кулларына күз иярми... Берничә метр китүгә – ике озын өстәл. Анысында балалар үз куллары белән рәсем ясыйлар. Ә әниләре өчен янәшәдә генә мастер-класс оештырылган. Дизайнер Нурия Умми һәм аның ярдәмчеләре хатын-кызны мөслимәчә яулык ябарга һәм зәвыклы киенергә өйрәтәләр.

Паркның икенче башында – «бабай» һәм «әби» оештырган мастер-класслар. Бәйләм серләренә төшенергә теләүчеләр «әби» янына җыелган. Үзләренең һөнәрләрен күрсәтергә ашкынучы малайлар – «бабай» янында. Нәни генә бер малай кулларына таянды да, гәүдәсен җирдән аерып, «тәгәрмәч» ясап, әйләнеп тә китте. Әлбәттә, «бабай» аңа шунда ук приз тоттырды. Моны күреп, икенче бер малай фокус күрсәтү теләге белдерде...

Кыскасы, паркның кайсы гына ягына барма, йә берәр кызыклы уенярышка, йә мастер-класска тап буласың.

Бала-чага һәм яшь-җилкенчәк, дөньяларын онытып, уеннарда, ярышларда катнаша. Өлкәннәр исә үзара гәпләшә-гәпләшә, шуларны күзәтә.

«Йөрәк шатлана, җаннар сафлана. Карагызчы, балалы яшьләр күпме?! Мондый дини бәйрәмнәрнең тәрбияви әһәмияте бик зур», – дип сөенечен белдерде заманында К.Тинчурин исемендәге театрда эшләгән Флүрә ханым Фазлыева. Аның сүзләрен рус милләтеннән булган дус хатыны, табиб Людмила Попова да куәтләде: «Монысы – безнеке, тегесе – сезнеке дип аермыйбыз. Татарстанда бергә яшибез, шулай булгач, бәйрәмнәребез дә уртак».

Бу сүзләргә өстәп, тагын ни дисең инде?! Ураза бәйрәмен оештыручылар әйтмешли, эштә дә, тормышта да, бәйрәмнәрдә дә бергә булыйк. Татарстан халкының көче – бергәлектә, бердәмлектә.

■ **Фирая Моратова**



# Табигать – адәм балаларына әманәт



Аллаһы Тәгалә Адәм галәйһиссәламне һәм аның кабыргасыннан яратылган Хәва анабызны иң элек җәннәттә яшәтте. Ләкин шәйтан ләгънәтуллаһ вәсвәсәсе белән икесе дә Җиргә төшерелде. Шул заманнан бирле адәм балалары соңыннан янәдән Раббылары хозурына әйләнеп кайту өчен шушы Җир шарында гомер итә. .

Раббыбыз Адәм галәйһиссәламне яратты һәм аны Җирдә хәлифә итте. Бу хакта Аллаһы Тәгалә «Әл-Бәкара» сүрәсендә:

**«Ул – Аллаһы җирдәге барча нәрсәне сезнең өчен халык кылды, соңра күкне төзергә теләде һәм күкне җиде кат итеп тергезде. Ул һәрнәрсәне белүче. Һәм әйтте синең Раббың фәрештәләргә: «Мин, әлбәттә, җир өстендә хәлифә итеп Адәмне кылмакчымын. Фәрештәләр әйттеләр: «Ий, Раббыбыз! Бозыклык кылучы, сугышып кан түгүче затны җир өстенә хәлифә кыласыңмы? Без исә Сине мактап тәсбихләр әйтәбез, һәм Сине һәр кимчелектән пакьсең дип игътикад итәбез». Аллаһы Тәгалә фәрештәләргә: «Дәреслектә, Мин сез белмәгәнне беләмен»,** – дип әйтә.

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:29-30

Шулай итеп, без яшәгән Җир шары: табигате, сулары, һавасы, хайванбөҗәкләре – барысы да безгә әманәт итеп бирелде. Шуңа да аны саклап тоту – һәрберебезнең изге бурычы.

Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм хәдис-шәрифендә: «Әгәр иртәгә Кыямәт буласын белсәң, бүген агач утырт», – дип әйткән. Шушы нәсыйхәтнең асыл мәгънәсе, әлбәттә, изгелек кылу турында. Ягъни кояш кире яктан чыкканчы, җаныбыз бугазыбызга терәлгәнче хәерле гамәлдә булырга тиешбез. Шул ук хәдиснең турыдан-туры мәгънәсе дә бик матур. Чөнки агач утырту – ул шулай ук изгелек. Аллаһы Тәгалә безгә табигать аша бихисап байлык бирә. Сулар һавабыз, эчәр суыбыз, ашар ризыгыбыз – барысы да әйләнә-тирәбездә, әмма Раббыбыз насыйп итмәсә – шушы нигъмәтләрнең берсен дә татый алмаячакбыз. Бер сулыш алырга да интегүчеләр, бер тәгам ризык каба алмаучылар бар – болар барысы да безгә бер кисәтү.

Шул агачны утыртуыбыз да, ниятебезгә карап – күркәм гамәл. Шушы агач һаваны чистартыр. Җимеш агачы икән – шул нигъмәтләр белән кешеләр, кошлар, хайваннар ризыкланыр. Еллар узып, бу агач зур булып үсәр, җәелер. Юлчылар эссе көндә аның күләгәсендә хәл алыр. Без инде ул вакытта бакыйлыкка күчкән булырбыз. Ин шә Аллаһ, шул утырткан агачыбыз, садакатуль-җәрия булып, кешеләр, башка җан ияләре аннан файда күреп, безгә савабы ирешеп торыр.

Мөхтәрәм дин кардәшләрем! Табигать мәсьәләсендә бик сак булсак иде. Аллаһының Илчесе Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләм хәтта афәт килгән авыр чакларда да, әйтик, сугыш вакытында да табигатькә зыян салмаска куша. Хәтта сугыш вакытында да! Ә бездә бүген, әлхәмдүлилләһ, сугыш юк, ләкин табигатькә каршы әллә нинди вәхшәтләр кылабыз. Үзебез шунда яшибез, үзебез шул җирдән алынган ризыкны ашыйбыз – үзебез шушы нигъмәтләрне исраф итәбез. Икенче бер хәдисендә Рәсүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйтә: «Һәрбер исраф – харам».

Җыелы чаклар җиттеме – табигатькә чыгабыз. Ял итәбез. Үзебезнең артыбыздан өем-өем чүп калдырабыз. Учак ягабыз дип, япь-яшь тап-таза агачларны балта белән чабабыз. Аннары: «Бетерделәр бөтен урманнарны», – дип зарланабыз. Инде бүген агач утырту түгел, булганнарын саклау турында да уйланмыйбыз. Раббыбызга шөкер, авылларда әле бакчаларда агачлар үсә, ә шәһәрләрдә яшелләкләр кими. Хәтта шул паркларда утыртылган агачларны да әшәкелек белән әледән-әле сындырып торалар. Кемнәр? Ерткыч хайваннар түгел – үзебез, шушы Җирнең хәлифәләре. Гәрчә Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм шул агачның яфракларын да сәбәпсез өзмәгез, дисә дә. Шуңа да балаларыбызны кечкенәдән өйрәтик: агачны сындырма, хайваннарны рәнҗетмә, суны пычратма! Үзебез дә шушы мәсьәләдә үрнәк булыйк.


Сәнәгать үсеше соңгы дистә елларда күп кенә урман-суларны юк итте, пычратты. Бу дөнья күләмендә шулай. Әлеге мәсьәләне, ин шә Аллаһ, хәл итү насыйп булсын. Ил җитәкчеләренә, сәнәгатьчеләргә Аллаһы Тәгалә күркәм гакыл бирсен. Аңлашыла: җитештерү, адәм баласын тәэмин итү кирәк. Шул ук вакытта табигать ресурсларыннан сак куллану программаларын да гамәлгә ашыру әһәмиятле. Монысы глобаль мәсьәлә. Без үзебездән башлыйк. Кайбер җирлекләрдә күрәбез: елга буенда гаҗәеп гүзәл бер авыл утыра, ә якынрак килсәң: канализация чокырын казымас өчен юынтык суларын шул елгага җибәрәләр. Расүлебез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм елга-суларга хәтта кече йомышыгызны да үтәмәгез, дип әйтеп калдырган! Табигать сакчылары Идел-суыбызны чистартканда нәрсә генә чыгармый. Үз кулларыбыз белән үзебез шул суга аткан чүпләр бит. Өйләребезне, каралты-кураларыбызны даими чистартып торыйк. Шәхси йортта торабызмы, фатирдамы – барыбер шул җирдән йөрибез. Берәр чүп ташладыкмы, гөнаһлы булырбыз. Пычрак күреп, шул урынны пакьләдек исә – ин шә Аллаһ, савап алырбыз.

Чүп мәсьәләсе бүген гомумән көн үзәгендә. Һәр кешедән көн саен әллә ничә килограмм чүп чыга. Бер күпкатлы йорттан контейнер-контейнер чүп алып китәләр. Бер шәһәр чүплегенә көн дә әллә никадәр машина чүп-чар китерелә. Ә бит шул ташлаган әйберләрне яңадан кулланып була. Кәгазь-картонны макулатура итеп тапшыра алабыз. Пластик әйберләрне эшкәртүгә тапшыру аеруча мөһим, чөнки ул таркалсын өчен 100-300 ел үтү кирәк. Агач утырттыкмы-юкмы, ул агач үстеме-юкмы, ә бүген чүп савытына ташлаган пластик шешәбез, пакетыбыз әле тагын 10 буын оныкларыбызга да калачак. Һич кенә дә күркәм мирас түгел бу.

Әлбәттә, бар чүпне бер капчыкка салып ташлап китү җайлырак. Берәр уйсу җирдә, урман эчендә аударып китү дә әллә ни көч сорамый. Ләкин мөселман кешесе хәтта шул чүп ташлауда да Ахирәт турында онытмаска тиеш. «Раббым биргән нигъмәтләрне пычратмыйм», – дип ниятләп эшкәртеп була торган чүпләрне аерым җыябыз икән – ин шә Аллаһ, савап. Шул макулатураны, пластик әйберләрне, иске батарейкаларны кабул итү пунктларына илтәбез икән – шулай ук әҗерен күрербез, Аллаһы боерса.

Гомумән, бүген чүплек янынннан үткәндә хәтта ризык та күрәбез. Бу бик куркыныч күренеш. Дөньяда күпме кеше ачлыктан интегә, ә без исә Раббыбызның нигъмәтләрен әнә шулай исраф итәбез. Берәр нәрсәнең кадерен белмәсәк, Аллаһы Тәгаләнең безне шул нигъмәттән мәхрүм итүе дә бар. Шуңа да ризыкны кирәгенчә генә алыйк, сакчыл карыйк. Күршеләребез белән дә бүлешик, әмма бозылыр дәрәҗәгә җиткермик, исраф кылмыйк. Табигатькә, Раббыбыз биргән нигъмәтләргә шөкер кылучылардан булыйк. Ин шә Аллаһ, шунда бәрәкәт тә булыр.

■ **Рөстәм хәзрәт Хәйруллин,**
**Казанның «Гаилә»**
**мәчете имам-хатыйбы**



## Мөмкинчелеге булганнарга хаҗны кичектерергә ярыймы?

**Сорау: Мөмкинлек туган очракта, хаҗны шул ук елда кылу мәҗбүриме, әллә соңрак та ярыймы?**

**Җавап:** Бу мәсьәләдә галимнәр арасында фикер төрлелекләре бар. Бу фикер каршылыклары ике имам – Әбү Йосыф һәм Мөхәммәд рахмәтуллаһи галәйһимнәр – арасында туа.

Әбү Йосыф рахмәтуллаһи галәйһи фикеренчә, барлык шартларны үтәргә мөмкинлек тугач та, хаҗны шул ук елда үтәү фарыз. Ә имам Мөхәммәд рахмәтуллаһи галәйһи хаҗ кылу мәҗбүри була, ләкин шул елда ук түгел, дигән фикер яклы. Ягъни кеше хаҗны бу елда һәм киләсе елларда да кыла ала. Имам Әш-Шафигый рахмәтуллаһи галәйһи дә шушы фикердә торган. Ә имам Әгъзам рахмәтуллаһи галәйһимнән ике фикер дә китерелә, ягъни «мөмкинлек тугач ук фарыз» һәм «фарыз, ләкин вакыт белән чикле түгел».

Иң элек имам Мөхәммәд рахмәтуллаһи галәйһинең карашын карап үтик: Аллаһы Тәгалә хаҗны фарыз кылган, ләкин аны вакыт белән чикләмәгән. Коръәни Кәримнең түбәндәге аятендә әйтелә:

**«Көче җиткән кешеләргә Аллаһыга гыйбадәт өчен хаҗ кылу фарыз».**

«Әли Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:97

Хаҗны үтәү вакытына килгәндә, Коръәндә Аллаһы Тәгалә:

**«Хаҗ кылу мәгълүм булган айлар, ягъни шәүвәл, зөлкагъдә, һәм зөлхиҗҗәнең ахыргы ун көннәре»,** – дип әйтә.

«Әли Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:197

Бу аятьләрдән шунысы аңлашыла, хаҗны төрле елда, ләкин билгеле айларда кылырга ярый. Коръән безне вакыт белән чикләми һәм шуңа да хаҗны бу елда (ягъни мөмкинлек туган елда ук) кылу мәҗбүри дип раслау нигезсез.

Шуны да искәртеп үтик, Мәккәне яулау һиҗри 8 нче елда була, ә сөекле Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вә сәлләм хаҗны бары тик һиҗри 10 нчы елда гына кыла. Әгәр дә хаҗны ашыгыч рәвештә кылырга кирәк булса, Пәйгамбәребез галәйһиссәлам аны үтәүне кичектермәс иде.

Әбү Хәнифә һәм Әбү Йосыф рахмәтуллаһи галәйһимнәрнең карашларын карап үтик. Хаҗ кылу вакыт белән чикләнмәгән. Ягъни аны мөмкинлек туу белән шул ук елда һәм киләсе елларда да кылырга була. Ләкин мөмкинлек туу белән кылсаң, ышанычлырак. Әгәр кеше бу фарыз гамәлне кичектерсә, тора-бара бөтенләй дә хаҗ кылырга мөмкинлеге булмавы бар. Имам Мөхәммәд рахмәтуллаһи галәйһи фикерен алсак, хаҗ кылырга мөмкинлеге була торып та, аны кичектерүчеләргә бу зарар китерергә мөмкин. Ә инде ашыгыч рәвештә хаҗны кылырга кирәк дигән фикерне алсак, бу күпкә ышанычлырак. Имам Әбү Мансур Әл-Матуриди рахмәтуллаһи галәйһи дә шул ук фикердә торган. Аның фикеренчә, вакыт белән чикләнмәгән теләсә нинди фәрманны (әмер) үтәгәндә, якын арада, ягъни шул вакытта башкаруны аңларга кирәк.

■ **Камил хәзрәт Сәмигуллин, ТР мөфтие**

## Зәкятне тапшыру кагыйдәләре

**Сорау: Кеше мәчет төзү, мәчеткә келәмнәр алу ниятеннән зәкят түләргә теләсә, бу зәкят булып саналамы?**

**Җавап:** Ниятсез зәкят түләү дөрес саналмый.

Зәкят түбәндәге кешеләргә түләнә:

1. Фәкыйрьләргә – мал-мөлкәте нисаб күләменнән азрак кешеләр (минимиль күләме якынча 230 мең).

2. Мескеннәргә – ул бернәрсәләре дә булмаган, йортларында берниндди уңайлыклары да булмаганннар.

3. Коллыктан котылырга теләүче кешеләргә. Бүгенге көндә безнең җирлектә андыйлар инде юк.

4. Бурычын түли алмаучы кешеләргә – бирәчәк бурычлары бөтен мал-мөлкәтеннән күбрәк булганнар.

5. Аллаһы Тәгалә юлында йөрүчеләргә. Әбү Йосыф рахмәтуллаһи галәйһи фикеренчә, болар – Аллаһы юлына чыга алмаган (хаҗ кылырга теләүче) ярлылар. Ә Әбү Мөхәммәд рахмәтуллаһи галәйһинең фикеренчә, болар – хаҗларын дәвам итә алмаучылар (ягъни элегрәк хаҗ кылучылар Мәккәгә җәяү барганнар. Юлларын дәвам итәр өчен аларның акчалары булмаган. Бу хаҗ кылучыларга акча бирергә, ягъни зәкят түләргә ярый). Әбү Йосыф рахмәтуллаһи галәйһинең фикере дөресрәк.

6. Юлда, сәфәрдә акчасыз калучыларга. Алар мөселман булса – зәкят бирелә. Аңа зәкяттән үзенә тиешле күләмдә алу рөхсәт ителә, ләкин кирәгеннән артыграгын алу хәләл саналмый.

Барлык галимнәрнең дә уртак фикере буенча, бер белмәгән кешегә зәкят бирү рөхсәт ителми. Шулай ук зәкят акчасына мәчетләр, күперләр төзү, юллар салу һәм хаҗга бару рөхсәт ителми.

Дөрес ният – зәкят түләүнең бер шарты булып тора. Шуңа да күңелдән бирeләчәк акчаның зәкят булын ниятләп әйтергә кирәк. Әгәр инде, тиешле сумма ният әйтелмичә генә бирелсә, ул акчалар әле кулланылмаган булса, зәкят түләүче күңеленнән бу акчаның зәкят буларак бирелүен билгели һәм бу рәвешле түләү дөрес булып санала. Зәкят алучы булмаганлыктан, зәкят суммасын мәчет төзүгә һәм келәмнәр алуга тотарга ярамый.

■ **Камил хәзрәт Сәмигуллин, ТР мөфтие**

## Тәһарәт алган вакытта аякларны дымлы салфеткалар белән сөртсәң ярыймы? Тәһарәтне кар белән алырга ярыймы?

**Сорау: Эштә чакта, тәһарәт алганда гел дә аякларны юып тору уңайсыз. Бу очракта аякларны дымлы салфеткалар белән сөртсәң ярыймы? Бу тәһарәт булып саналамы? Мин Рәсәйнең үзәк өлешендә яшим һәм еш кына урамда булырга туры килә. Миңа тәһарәтне кар белән алсам ярыймы?**

**Җавап:** Иң элек «госел» (коену) һәм «мәсех» сүзләренең мәгънәләрен карап үтик. «Коену» – тәннең һәр өлешенә дә су ирешү. «Мәсех» –тәннең өлешләрен юеш кул белән сыпыру. Әгәр дә кеше тәһарәт алганда, тәннең юылырга тиешле өлешләреннән су акмаса (ягъни бер-ике тамчы су да таммый), ул суны тәнгә май сөрткән кебек кенә кулланган булып санала (су таммады). «Заһир Әр-Ривайә» буенча болай рөхсәт ителми.

Кар белән тәһарәт алу мәсьәләсенә килгәндә, галимнәр түбәндәге фикердә торалар: әгәр кеше кар ярдәмендә тәһарәт алса, ләкин тәненнән су таммаса, тәһарәт саналмый. Әгәр инде кар эреп, куллардан тамса, тәһарәт булып санала. Факыйһ Әбү Җәгъфар Әл-Хиндуванидан тәһарәтне кар ярдәмендә алу хакында сорагач, ул: «Бу тәһарәт алу түгел, бары тик «сыпыру». Әгәр кеше кар эреп, ике-өч тамчы су тамарлык дәрәҗәдә тәнен сыпырса (ышкыса), бу тәһарәт булып санала», – дип җавап кайтарган.

■ **Камил хәзрәт Сәмигуллин, ТР мөфтие**

## Мәрхүм исеменнән садака бирергә ярыймы?

**Сорау: Үлгән кеше исеменнән садака бирсәң ярыймы?**

**Җавап:** Әгәр кеше үлгән кеше исеменнән садака биреп һәм аның рухына дога кылса, бу гамәл рөхсәт ителә. Моның әҗер-савабы үлгән кешегә ирешәчәк. «Хизәнәтүл-Фәтәвә» китабында шулай әйтелә.

Ә Аллаһыга яхшырак мәгълүм.

■ **Камил хәзрәт Сәмигуллин, ТР мөфтие**

# Мөселманнар Изге Болгар җыенын билгеләп үттеләр









Болгар дәүләт тарих-архитектура музей-тыюлыгы территориясендә Идел буе Болгар дәүләтендә Ислам динен рәсми кабул итү көненә багышланган тантаналы «Изге Болгар җыены» чарасы узды. Бәйрәмдә Россиянең төрле төбәкләреннән күпсанлы мөселманнар, Татарстан Республикасы җитәкчелеге, дин әһелләре лидерлары, муниципаль берәмлекләр башлыклары, министрлыклар һәм ведомстволар җитәкчеләре, Россия Федерациясе төбәкләреннән мөселман дин әһелләре катнашты.

Бәйрәм Яшел Үзән районы имаммөхтәсибе Габделхәмид хәзрәт Зиннәтуллинның изге Коръән аятьләре укуыннан башланды һәм республика солистлары башкаруында мөнәҗәтләр һәм нәшидләр, шулай ук Татарстанның баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыев һәм ТР мөфтие урынбасары Илфар хәзрәт Хәсәновның вәгазьләре белән дәвам итте.

Тантанада катнашучыларны Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов, Россия мөселманнарының Үзәк Диния нәзарәте рәисе Тәлгать Таҗетдин, Татарстан мөселманнары башлыгы, республика мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин, шулай ук Мәскәү, Чечня, Дагъстан, Ингушетия, Кырымның мөселман дин әһелләре сәламләде.

Җыенның мөртәбәле кунаклары булып төрле дәрәҗәдәге дәүләт җитәкчеләре дә торды: Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәрип улы Шәймиев, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе Әсгать Сафаров, Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары, Бөтендөнья татар конгрессының «Милли советы рәисе Васил Шәйхразиев, Россия Федерациясе Президентының эчке сәясәт буенча идарәсенең дини оешмалар белән хезмәттәшлек департаменты башлыгы Евгений Еремин катнашты, милләтләр эшләре буенча Федераль агентлык җитәкчесе урынбасары Михаил Мишин, Казан һәм Татарстан Митрополиты, владыка Феофан.

Рөстәм Миңнеханов ассызыклаганча, соңгы 10 елда борынгы Болгар җирлегендә бик зур үзгәрешләр булды. Татарстан Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев җитәкчелегендә, бу җирдә искиткеч туристик үзәк булдырылып, бөек тарихи мирасны торгызуга ирешкәннәр, дип билгеләп үтте ул.

Минтимер Шәймиев Борынгы Болгарны торгызу буенча масштаблы эштә бөтен республика катнашты, дип өстәде. «Бу Безнең мирас. Алга таба эшне дөрес итеп оештырырга, эчтәлекле өлешен үстерергә һәм баетырга кирәк. Бу безнең җир, монда безнең тарих. Аны сакларга кирәк!» – диде ул. Аннары «Мәдәни мирас: Свияжск утрау-шәһәре һәм Борынгы Болгар» комплекслы проектын гамәлгә ашыруга аерым өлеш керткәне өчен Минтимер Шәймиев Татарстан Президенты Рөстәм Миңнехановка «Яңарыш» Республика фонды Хәйриячеләре киңәшәсенең IX томын тапшырды. Минтимер Шәрипович кулыннан рәхмәт сүзләре белән бергә шундый ук бүләкне республика мөселманнары башлыгы Камил хәзрәт Сәмигуллин да алды.

Мөфти хәзрәт үз чыгышында чарада катнашучыларга Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең хәдисе белән мөрәҗәгать итте: «Биш нәрсә килгәнче биш төрле әйбернең кадерен бел: картлык килгәнче яшьлегенең, авыру-сырхау килгәнче сәламәтлегенең, фәкыйрьлек килгәнче байлыгының, мәшәкатьләр килгәнче буш вакытның, үлем килгәнче яшәүнең». Аннары шушы хәдискә ияреп: «Милләтебезне югалтмас өчен, үз динебезне сакларга һәм бәяләргә тиешбез», – дип йомгаклады ул сүзен.

Әлеге чараның иң мөһим өлеше булып Җәмигъ мәчете территориясендә җәмәгать белән өйлә намазын уку булды. Камил хәзрәт дин тотучыларны дога кылырга чакырып азан әйтте, Тәлгать хәзрәткә ияреп намаз кылынды. Намаз укуда шулай ук Рөстәм Миңнеханов, Минтимер Шәймиев һәм башка мөртәбәле кунаклар катнашты.

■ dumrt.ru

# Болгар җыенында Минтимер Шәймиев мөселман дин әһелләре белән очрашты



Болгар җыены вакытында ТР Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев мөселман дин әһелләре белән очрашу үткәрде. Әлеге чарада Россиянең төрле төбәк мөфтиятләре вәкилләре, Татарстан имамнары һәм мөхтәсибләре, дәүләт һәм җәмәгать эшлеклеләре, галимнәр катнашты. Моннан тыш, чит ил кунаклары арасында Төркиянең Казандагы баш консулы Әхмәт Садыйк бәй Доган, Бәхрәйннең Югары шәригать суды рәисе Ибраһим Әл-Мурейхи, катнаш көрәш буенча дөнья чемпионы Олег Тактаров һ.б. бар иде. Сөйләшүдә Татарстан вәкилләреннән шулай ук ТР Дәүләт Советы рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Разил Вәлиев һ.б. катнашты.

Очрашу махсус чатырда эшлекле аралашу белән башланып китте: Минтимер Шәрип улы Шәймиев Төркиядән килгән фән эшлеклеләрен, тарихчыларны тәкъдим итте. Аларның хәзерге вакытта Шәһре Болгар җирлегенә Алтын Урда тарихын өйрәнү өчен килгәнлекләрен ассызыклап узды.

Алга таба ТР Дәүләт Киңәшчесе һәрбер дин әһеленә үзенең эчкерсез сәламнәрен җиткерде, дин башлыклары белән күрешеп чыкты, Болгар җыеныннан алган тәэсирләре белән уртаклашты. Кунаклар шулай ук быелгы җыенда беренче тапкыр уздырылган көрәш ярышын дәвамлы итү, Болгар ислам академиясе янәшәсендә җәйге балалар лагерен оештыру мәсьәләләре буенча кыскача үз фикерләрен әйттеләр.

Дин әһелләре үз чиратында шәһре Болгарда тарихи мирас һәйкәлләрен торгызу һәм яңарту буенча фидакяр хезмәте өчен ТР Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев адресына иң зур рәхмәт сүзләре яңгыратты. Үз чиратында, Болгар җыенын хөрмәт итеп килгән һәм аны уздыруда теләктәшлек күрсәткән дин әһелләренә Минтимер Шәймиев шулай ук тирән ихтирамын белдерде: «Болар барысы да безнең бергәләп кулга-кул тотынышып эшләгән эшләребез. Югары дәрәҗәдә Болгар җыенын уздыру сездән башка мөмкин булмас иде», – дигән сүзгә җавап итеп, Татарстанның баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыев уенынчынын бергә кушып: «Без барыбыз да вагон кебек. Әмма аны тартып баручы паровоз булмаса, вагоннар тик торыр иде», – дип җавап бирде. Россия төбәкләреннән килгән мөфтиләр, татар дин эшлеклеләре исеменнән рәхмәт сүзләрен Ханты-Манси автономияле округы мөфтие Таһир хәзрәт Саматов җиткерде. Ул Татарстан Республикасында бай рухи мирасны саклау буенча әһәмиятле эшләр башкарылуына тукталып үтте, шулай ук Татарстан мөфтияте тарафыннан күренекле дин әһеле Габделхак хәзрәт Саматовның укулары уздырылу, китаплары бастырылуны уңай бәяләп, рәхмәтен әйтте.

Очрашу ил-көнгә бәрәкәт теләп догалар кылу белән тәмамланды.

■ dumrt.ru

# Беренче мөселман хастаханәләре (бимаристаннар) нинди булган?

Бимаристан (фарсы теленнән «хастаханә» дип тәрҗемә ителә) – дәвалану үзәге дә, төрле чирләрдән һәм бәхетсезлек очракларыннан соң савыгу йортлары да, караучылары булмаган кешеләр өчен картлар йорты да һәм психологик ярдәм күрсәтә торган тернәкләнү урыны булып та хезмәт иткән.

## Мобиль диспансерлар

Медицина ярдәме күрсәтә торган беренче танылган ислам үзәге Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм яшәгән чорда, Руфайдә Әл-Әсләмия палаткасында оеша. Тарихтан билгеле, Хәндәк сугышы вакытында ул әлеге палаткада яралыларны дәвалаган.

Соңрак хакимнәр мондый палаткалардан чын юл диспансерлары ясаганнар, чөнки анда дарулар, ризык, эчемлекләр, кием-салым, табиблар һәм фармацевтлар да булган.

Алар хакимнәргә дә ярдәм күрсәткәннәр. Шунысы кызык, сәлҗүк солтаны Мөхәммәд Сәлҗүки идарә итә башлаган дәвердә бу мобиль хастаханәләр шундый зур булганнар ки, аларны күчерергә хәтта 40 дөя кирәк булган.

## Хастаханәләр

Беренче мөселман сырхауханәсе булып лепрозорий торган. Ул VIII гасыр башында өмәвиләр хәлифәсе Вәдид бине Габделмәлик идарә иткән чорда Димәшкъта төзелгән. Анда эшләгән медицина белгечләренә күп хезмәт хакы түләнгән. Монда яткан авыруларның хәрәкәтләре чикле булганга (махау (проказа) чире йогышлы булган), аларга стипендияләр түләнгән. Шул рәвешле алар гаиләләрен тәэмин итә алганнар.

Документларда да расланган иң беренче хастаханә 805 елда Багдадта, Һарун Әр-Рәшид тарафыннан төзелгән. Соңрак тагын 34 хастаханә барлыкка килгән һәм аларның саны елдан-ел арткан.

Тарихи истәлекләрдән билгеле, Гали бине Гайсә бине Җәрах бине Табит исемле вәзир X гасыр башында Багдадның баш табибына болай дип язган: «Мине бигрәк тә ирекләреннән мәхрүм булганнарның язмышы борчый. Аларның бик күп санда булуларына һәм төрмәләрдәге яшәү шартларына караганда, алар арасында бик күп авырулар бардыр дигән фикер туа. Шуңа да, мин аларның үзләренең аерым табиблары булырга тиеш, дип саныйм. Ул табиблар аларны һәркөн карарга, тиешле даруларын һәм төнәтмәләрен бирергә тиешләр. Мондый табиблар барлык төрмәләрдә йөреп, анда ирекләреннән мәхрүм булган авыруларны дәваларга тиешләр». Шушы хәлләрдән соң ирекләреннән мәхрүм булучылар өчен төрле уңайлыклары булган аерым хастаханә төзелгән.



Беренче булып IX гасырда барлыкка килгән мөселман хастаханәсе төрле бүлекләргә: хроник авырулар, хирургия, офтальмология, ортопедия һәм психик авырулар бүлегенә бүленгән. Хроник авырулар бүлеге үз эчендә тагын бизгәк, ашкайнату, инфекцияләр белән бәйле булган аерым бүлекчәләргә аерылган. Зуррак хастаханәләрдә бүлекләр һәм бүлекчәләр саны тагын да күбрәк булган.

Табиблар билгеләнгән вакытта эшләгәннәр. Һәрбер хастаханәнең үз фармацевтлары, шәфкать туташлары булган. Шунысын да әйтеп китәргә кирәк, баш табиб һәм даруханәче вазифалары дәүләттә иң югары дәрәҗәләрдән саналган.

Мөселман хастаханәләре васыять итеп бирелгән керемнәр хисабына (вакф) яшәгән. Бай кешеләр һәм хакимнәр милекләрен эшләп килгән һәм яңа гына төзелгән хастаханәләргә садака буларак биргәннәр. Васыять итеп бирелгән керемнәр исә төзелеш эшләренә тотылган. Дәүләт бюджетының бер өлеше шулай ук хастаханәләрне тоту өчен күчерелгән. Авырулар өчен дәвалану нигездә бушлай булса да, кайбер табиблар моның өчен акча да сораганнар.

## Хастаны карау

Бимаристаннар тәүлек дәвамында ачык булганнар. Аларда ир-ат һәм хатын-кыз табиблар да эшләгән. Шулай ук ир-атларга һәм хатын-кызларга аерым бүлекләр булган.

Хастаханәдә ятып дәваланган хасталарга аерым киемнәр, чиста урынҗир бирелгән. Үз киемнәре исә хастаханәнең кибетендә сакланган. Палаталар да чиста һәм уңайлы булган. Инспекторлар һәркөн хастаханәнең чисталыгын карап торганнар. Дәүләт җитәкчеләре дә бик еш хастаханәгә килеп, авыруларның тиешле медицина ярдәме алуларын тикшереп торганнар.

Авыру хастаханәгә килгәч үк табиб тарафыннан билгеләнгән дәвалану курсы башланган. Һәрбер хаста кешегә үзенең шәхси картасы ачылган. Табиб анда хастага бәйле төрле күзәтүләрен теркәп барган. Авыруның хәленә һәм чиренә карап, тиешле диета билгеләнгән. Ашаган ризыклары сыйфатлы булган. Катлаулы чирләр булган очракларда, табиблар киңәшләшү һәм яшь табибларга консультацияләр бирү максатыннан бергә җыелып очрашу-консилиумнар оештырганнар.

Әгәр кеше билгеле бер күләмдә ипи һәм кыздырылган бер кош итен ашап бетерсә һәм аның организмы бу ризыкларны җиңел үзләштерсә, кеше дәваланган, сәламәт дип санаганнар, шул рәвешле кешенең сәламәтләнүенә бу төп критерий булган.

Кеше дәвалану курсы узып, ләкин әле көчсез булса, аны савыгучылар бүлегенә күчергәннәр. Мохтаҗ булган авыруларга хастананәдән чыккач яшәр мөмкинлеге булсын өчен яңа кием һәм аз гына булса да акча бирелгән.

Кайвакыт, медицина ярдәменең сыйфатына дәгъва белдерелеп, суд эшләре дә кузгатылган. Әгәр хаста кеше вафат булса, аның әти-әнисе баш табибка мөрәҗәгать иткәннәр. Алар аңа табиб язып биргән рецептларны күрсәткәннәр. Әгәр дә инде баш табиб, хастаны дәвалаган табиб үз эшен тиешенчә башкарган дип санаса, ул бу әти-әнигә үлемнең табигый булын, ягъни табибның гаебе булмавын хәбәр иткән. Әгәр дә инде чыннан да хастаның үлеме табиб ялгышлыгы сәбәпле булса, баш табиб бу әти-әнигә: «Табибтан туганыгызның акчаларын алыгыз, ул аны үзенең игътибарсызлыгы аркасында үтерде», – дип әйткән.

Зур шәһәрләрдә гадәти хастаханәләр белән беррәттән ашыгыч һәм кичектергесез ярдәм күрсәтү үзәкләре дә эшләп килгән. Гадәттә алар зур мәчетләр янында урнашкан булганнар.

## Медицина мәктәпләре һәм китапханәләре

Хастаханәләрдә авыруларны дәвалау гына түгел, ә табиблар әзерләүгә дә зур игътибар бирелгән. Һәрбер хастаханәдә шактый зур гына лекцияләр залы булган. Анда студентлар семинарлар үткәргәннәр. Алар олырак табиблар белән палаталарга йөреп, авыруларның хәлләрен белешкәннәр, аларга ярдәм иткәннәр. Укулары имтихан тапшырып, медицина практикасы буенча лицензия алу белән тәмамланган. Ләкин иң элек кандидат билгеле бер темага трактат язып, аны якларга тиеш булган.

Хастаханәләрнең студентлар һәм мөгаллимнәр өчен тагын бер әһәмиятлеге ягы, ул да булса – хастаханәләрдә медицина китапханәләренең булуы. XIV гасырда Мисырдагы Ибне Тулун исемендәге китапханәдә медицинаның төрле өлкәләренә караган барлыгы 100 000 китап исәпләнгән. Шунысы кызык, бу исә Европадагы күренекле Париж университетының китапханәсе үзенә 400 том сыйдырган вакытка туры килгән.

Шул рәвешле, бимаристаннар ислам медицинасының бишеге һәм хәзерге больницаларның прототибы булып, урта гасыр ислам дөньясының күренекле фәнни ачышларының берсе булып саналган.

■ islam-today.ru

# Рамлә бинте Әбү Суфиян радыяллаһу ганһә



## Ислам динен кабул итүе

Әбү Суфиян бине Хәрб Мәккәнең җитәкчесе булганга, аңа бөтенесе дә буйсынганнар һәм ияргәннәр, беркем дә аңа каршы килергә базмаган.

Әмма аның кызы Рамлә бу тәртипләргә каршы килгән. Ул ире Гобәйдулла бине Җәхш белән Аллаһы Тәгаләгә һәм Аның Илчесенә иман китергән.

Әбү Суфиян үзенең көчен һәм абруен кулланып, кызын һәм дә киявен бабалары диненә кайтарырга тырышып караган, ләкин нәтиҗәсе булмаган. Рамләнең (Өмме Хәбибә) калебендәге иманы шулкадәр нык булган ки, хәтта аны әтисенең тырышлыгы да юкка чыгара алмаган.

## Корәешлеләрнең эзәрлекләве

Аллаһының Илчесе Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм мөселманнарга Хәбәшигә (Эфиопия) һиҗрәт кылырга рөхсәт иткәч, Рамлә, кечкенә кызы Хәбибә һәм ире Гобәйдулла бине Җәхш үзләренең иманнарын һәм Аллаһының динен саклап калу, Хәбәши негусыннан ярдәм, яклау сорау өчен шул тарафларга качарга ниятлиләр.

Әмма Әбү Суфиян һәм Корәешнең башка җитәкчеләре мөселманнарның Хәбәшигә китеп, анда тыныч кына яшәүләренә риза булмаганнар. Алар Хәбәши негусы Нәҗашигә илчеләр җибәреп, аны качакларга каршы котырталар, аларны кире бирүен сорыйлар.

Нәҗашигә исә Ислам турында хакыйкатьне сөйләгәч һәм Коръәннән кайбер аятьләр укыгач, ул елап ук җибәргән. Үзенең бер Аллаһыга һәм Мөхәммәд галәйһиссәламнең пәйгамбәрлегенә иман китерүен игълан иткән.

Әлеге хәлләрдән соң Өмме Хәбибә барлык авырлыклар артта калып, якты көннәр җитте дип уйлаган. Ләкин Аллаһы Тәгалә аны тагын бер сынауга дучар иткән.

## Төшнең чынга ашуы

Бер төндә Өмме Хәбибә ире Гобәйдулланың диңгездә бата язуын, диңгез дулкыннары аны каплавын, ә тегесенең нәрсә эшләргә дә белмичә, һаман диңгез караңгылыгына керә баруын төшендә күрә.

Озакламый Өмме Хәбибәнең төше чынга аша: аның ире Гобәйдулла бине Җәхш Ислам диненнән баш тарта һәм насара диненә күчә. Шуннан соң «яшел елан» белән дуслашып, сәрхүшкә әйләнә.

## Ныклык һәм сабырлык

Өмме Хәбибә авыр сайлау алдында кала: яки аерылу, яки үзенә дә насара диненә күчү. Өмме Хәбибә бик нык уйлана, борчыла, кешеләрдән читләшә. Аның өчен бу бик авыр вакытлар була. Ниһаять, ул Хәбәшидә калырга һәм Аллаһы Тәгаләдән җиңеллек көтәргә дигән карарга килә.

Ире исә насара динен кабул иткәннән соң озак яши алмый, вафат була.

## Җиңеллек

Иренең вафатыннан соң, гыйддә вакыты тәмамлангач, Аллаһы Тәгалә аңа җиңеллек ирештерә.

Бер төнне Өмме Хәбибә төшендә үзенә Өмме мөэминин (Мөэминнәрнең анасы) дип дәшкәннәрен ишетә. Йокысыннан уянып, ул озакламый Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең аңа өйләнәчәген аңлый.

Кояшлы иртәләрнең берсендә аның ишеген кагалар. Ишеген ачкач, ул анда Хәбәши патшасының хезмәтче кызы Әбраһа торганын күрә. Өмме Хәбибә аңа керергә рөхсәт бирә. Хезмәтче кыз аңа болай дип әйткән: «Хәбәши патшасы сине сәламли һәм ул сиңа Мөхәммәд пәйгамбәрнең сине ячкылавын хәбәр итәргә кушты. Мөхәммәд галәйһиссәлам аңа хат җибәреп, патшаны никахта вәли булырга чакырган. Син үзең теләгән кешене вәлиең итеп билгели аласың».

Өмме Хәбибә бик нык куанган һәм шатланып: «Аллаһы Тәгалә сине шатлыклы хәбәр белән җибәргән!» – дип әйткән. Шушы шатлыклы хәбәр белән сөендергәне өчен, Әбраһаны бүләкләргә теләп, ул үзенең бизәнгечләрен салып, барысын да (алкаларын, йөзекләрен һәм беләзекләрен) шушы хезмәтче кызга биргән. Аның кулында барлык дөнья байлыклары булса да, ул шулвакытта рәхәтләнеп барысын да биргән булыр иде. Шуннан соң ул Әбраһага: «Минем вәлием Халит бине Сәгыйд бине Гас булачак, чөнки ул минем туганым», – дип әйткән.

## Никах мәҗлесе

Никах мәҗлесе Нәҗашинең бик матур һәм затлы сараенда узган. Никахта пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзе булмаса да, Хәбәшидә яшәгән күренекле сәхабәләр чакырулы булган. Алар арасында Җәгъфәр бине Әби Талиб, Халит бине Сәгыйд бине Гас, Габдулла бине Хозәйфә Әс-Сәһми һ.б. Алар бу никахның шаһитлары булганнар.

Мәҗлес тантанасын Нәҗаши ачып җибәргән. Ул Өмме Хәбибә радыяллаһу ганһәгә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең кушуы буенча мәһәр итеп дүрт йөз динар биргән. Шуннан соң инде кунакларны сыйлаган.

## Өмме Хәбибә һәм хезмәтче кыз Әбраһа

Өмме Хәбибә радыяллаһу ганһә болай дип сөйләгән: «Миңа акча китергәч, мин илле мыскал алтынны Әбраһага җибәрдем. «Син миңа хәбәр китергән көнне үк акча биргән булыр идем. Ләкин ул көнне минем акчам юк иде. Әмма тиздән Әбраһа минем яныма килде дә, алтыннарны һәм бизәнгечләрне кире кайтарды. Ул: «Патша синнән әлеге бүләкләрне алуны тыйды һәм хатын-кызларга үзләрендә булган ислемайларны сиңа бирергә кушты», – дип әйтте.

Икенче көнне миңа хуш исле сары агач, гамбәр китерделәр. Әбраһа миңа: «Минем сиңа бер үтенечем бар», – дип әйтте. Мин аннан нинди үтенече барлыгы турында кызыксындым. Ул минем соравыма: «Мин Ислам динен кабул иттем һәм Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм диненнән барам. Шуңа күрә, Мөхәммәд пәйгамбәргә миннән сәлам әйтергә онытма», – дип җавап кайтарды. Шуннан соң ул миңа бирнәмне әзерләде.

Мине Пәйгамбәр янына илттеләр. Аның белән очрашкач, мин мәҗлеснең ничек узганын, Әбраһа белән булган хәлләрне сөйләдем. Пәйгамбәргә аннан сәлам әйттем. Бу хәл Пәйгамбәрне бик тә шатландырды. Ул: «Аңа Аллаһының сәламе, рәхмәте һәм мәрхәмәте булсын», – дип әйтте».

## Өмме Хәбибә радыяллаһу ганһәнең дәрәҗәсе

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм Өмме Хәбибә радыяллаһу ганһәне яраткан һәм тирән хөрмәт иткән. Ул бик еш аның дәрәҗәсе турында искәрткән һәм «Өмме Хәбибә һәм аның абыйсы Могавия – җәннәттә булачаклар», – дип әйтә торган булган.

Өмме Хәбибә радыяллаһу ганһәнең дәрәҗәсенә килгәндә, иң элек аның Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең сөннәтенә иярүен атарга кирәк. Пәйгамбәребез галәйһиссәламнән берәр боерык ишетүгә, ул аңа бик теләп буйсынган һәм ул гамәлне даими үтәргә тырышкан.

Шулай ук Аллаһы Тәгаләгә якынаю, Аның ризалыгына ирешү өчен ул фарыз гамәлләрне һәм дә өстәмә нәфел гамәлләрне дә башкаруга бик игътибарлы булган. Иренең ризалыгына ирешү өчен дә ул зур көч куйган.

Иманлы мөслимә нәкъ шундый булырга тиешле дә. Аллаһы Тәгалә Коръәндә мөэминнәрнең аналарына мөрәҗәгать итеп, болай дип әйтә:

**«Өегездә укылган Аллаһының аятьләрен вә хөкемнәрен зекер итегез, Аллаһы бик нечкә нәрсәләрдән дә хәбәрдар булды».**

«Әхзаб / Гаскәрләр», 33: 34

## Рамлә бинте Әбү Суфиянның вафаты

Мөэминнәрнең анасы Рамлә бинте Әбү Суфиян (Өмме Хәбибә) радыяллаһу ганһә 665 нче елда, абыйсы Могавия бине Әби Суфиян радыяллаһу ганһе идарә иткән чорда 70 яшендә вафат булган. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән 65 хәдис тапшырган.

■ **«Шура» №25**

# Мәчет һәм балалар

Ислам дине таралгач та балаларны мәчеттә күрергә мөмкин булган. Әлбәттә, ул вакытта да инде балалар бүгенге кебек уйнаганнар, сикерешкәннәр, йөгергәннәр. Намаз вакытында елап та, көлеп тә җибәрә торган булганнар.

Риваятьләрдә хәбәр ителгәнчә, бервакыт Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм ачык урында сәхабәләр белән намаз кылган. Ибне Габбас (ул вакытта әле ул кече яшьтә булган) үзенең ике дусты белән ишәккә атланып, шушы җиргә килгәннәр. Болар Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм каршысыннан узып китеп, ишәктән төшеп, ишәкне намаз укучы сафлар арасына җибәргәннәр. Үзләре дә сәхабәләр арасында йөгерешеп уйнаганнар. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм һәм сәхабәләрнең берсе дә аларны бу гамәлләре өчен шелтәләмәгән. Шул рәвешле, олыларның мондый мөнәсәбәте балаларны җәмәгатьтән читләштермәгән, киресенчә, балаларда намазга һәм Аллаһының йорты булган мәчеткә мәхәббәт уяткан.

Икенче яктан караганда, ул вакытларда мәчетләр гыйбадәт кылу урыны гына булмаган. Мәчетләрдә дин гыйлеме дә өйрәтелгән, көндәлек, иҗтимагый һәм сәяси сораулар да хәл ителгән. Шуңа да мәчетләрдә балалар бик күп булган, хәтта алар аерым бер саф булып тезелеп баса торган булганнар. Мәчеттә булганда балалар мөселман кешесе нинди булырга тиешлеген, аңа нинди буычлар йөкләнүен өйрәнгәннәр.

Күп кенә риваятьләрдән билгеле булганча, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм кайвакытларда кулына берәр оныгын яки оныкчыгын алып намазын кыла торган булган. Ул сәҗдә кылган вакытта, алар аның аркасына менеп утырганнар. Алар җиргә төшмичә, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм сәҗдәдән күтәрелмәгән. Моннан күренгәнчә, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең оныклары кече яшьтән үк мәчеткә йөргәннәр дип әйтә алабыз. Шулай ук мәчеткә хатын-кызлар күкрәк балалары белән дә килгәннәр. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең болай дип әйткәне билгеле: «Аллаһының коллары булган хатын-кызларга мәчеткә йөрергә комачауламагыз». Мөхәммәд пәйгамбәр галәйһиссәлам балаларга мәчеткә йөрергә бернинди каршылыклар ясамаган, киресенчә, үзе аларны намазга өйрәткән.

Алда әйтеп үтелгәннәрдән күрәбез, төрле яшьтәге балаларның да мәчеткә тартылулары гадәти күренеш булган. Моны Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм бик яхшы аңлаган, алар турында кайгырткан һәм аларга шартлар тудырырга тырышкан.

## Мәчеткә ничә яшьтән йөрергә?

Баланы ничә яшьтән мәчет белән таныштырырга була соң? Кемдер «бик яшьтән», дип әйтер. Кемдер «үзе аңлый башлагач», дип җавап бирер. Ә кайберәүләр баланың үзенә сайлау мөмкинлеге калдырырлар. Шәригатьтә фарыз намазлар һәм башка мәсьәләләргә бәйле яшь күрсәткечләреннән кала төгәл күрсәтмәләр юк. Шуңа да алда санап кителгән очракларның барысы да дөрес кебек.

Шулай да кайбер кыенлыкларга игътибар итеп китик. Мәсәлән, күкрәк баласын үзен генә калдырырга ярамый, чөнки ул кычкырып елап җибәрергә мөмкин, ә гыйбадәт кылучы әнисе аны тынычландырыр өчен намазыннан бүленә алмаячак.

Бер яки ике яшьлек баланы да үзен генә калдыру ярамый, чөнки ул, әлбәттә, әти-әнисен көтеп, ялгызы гына тыныч утыра алмый. Ул сафлар арасында йөри, шаяра, көлә яки елый башлый. Кайбер аналар кызы яки улы олыларга карап, шул ук вакытта намаз хәрәкәтләрен ясый башлыйлар дип ялгышалар.

Бераз зуррак яшьтә булган балаларны да үзеңнән ераграк җибәрергә ярамый. Алар һәрвакыт яныңда булырга тиешләр. Әгәр 5-6 яшьлек бала һәрвакыт йөри торган мәчетенә унынчы яки йөзенче тапкыр намазга килгән очракта гына аңа бераз ирек бирергә була: ул үзе теләгән кешесе янына басып намаз укый яки бераз алгарак китеп, имамга якынрак баса ала; яки олылардан соң, дуслары белән үз «җәмәгатен» оештырып баса.

## Рәсемнәрдәге мәчет

Бала сораулар бирә башлагач, аңа тулы һәм аңлаешлы мәгълүмат бирү бик мөһим. Бу сорауларга җавапларны аның белән бергә тапсагыз, тагын да хәерлерәк. Балага төрле мәчетләр мисалында бөтен дөньяны күрсәтергә була. Мәсәлән, беренче мәчет нинди булган? Хәзерге вакытта дөньядагы иң зур мәчет кайда? Бу сорауларга әлеге мәчетләрнең рәсемнәрен күрсәтеп тә җавап бирергә була.

Буш тартмалардан яки картоннан ясалган мәчет мисалында намаз уку залын, минбәр, тәһарәтханә бүлмәсен билгеләргә була.

## Мәчет ул гыйбадәт кылу урыны гына түгел

Башка дин вәкилләренең гыйбадәтханәләреннән аерылмалы буларак, мәчет ул гыйбадәт кылу урыны гына түгел. Теләсә нинди пакь, нәҗес булмаган җирдә намаз укырга яраганлыгын балалар белергә тиеш. Моның өчен мәчеткә бару шарт түгел. Мәчетнең үзендә намаз уку гына түгел, дини дәресләр үткәрергә, бәйрәмнәр оештырырга да мөмкин.

Хәзер инде бала мөстәкыйль рәвештә мәчеттә үз-үзен ничек тотарга кирәклеге турында уйланырга мөмкин. Мәсәлән, башкалар намаз укыганда комачауларга ярыймы? Юк, әлбәттә. Димәк, намаз укылган вакытта йөгерергә, тавышланырга ярамый. Мәчеттә чүпләргә ярыймы? Әлбәттә, юк. Чөнки монда намаз укыла, ә намаз чиста, пакь җирдә укылырга тиеш.

## Баларга мәчеткә йөрүне тыяргамы?

Әлбәттә, балаларны мәчеткә йөрергә һәм күңелләрендә мәчеткә карата мәхәббәт уятырга кирәк. Ләкин шул ук вакытта мәчеттә чисталыкны сакларга һәм анда гыйбадәт кылучыга комачау итмәскә кирәк. Җәмәгать белән намаз укымаучы балалар өчен иң хәерлесе – намаз залының ахыргарак өлешендә яки мәчет ишегалдында уйнау. Аларның уйнаганнарын олылардан берәрсе карап торса яхшы. Әйткәнебезчә, балаларның мәчетне чүпләмәүләрен һәм уйнаган вакытларында гыйбадәт кылучыларга комачау итмәүләрен күзәтеп торырга кирәк. Кайбер мөселманнар балаларын җомга намазына алып киләләр. Җәмәгать намаз кыла башлагач, балалар сафлар арасында йөгерешә, кычкырып сөйләшә башлыйлар. Бу бер дә матур күренеш түгел. Әгәр дә бала әтисе янәшәсенә басып, намаз кыла ала икән, аны үзең белән мәчеткә алып килергә була. Әгәр инде бала үзе дә намаз укымый һәм башкаларга да гыйбадәт кылырга комачаулый икән, бу очракта аны мәчеткә алып килмәү хәерлерәк.

## Файдалы киңәшләр

Балалар булган мәчетләрдә тавыш һәм дә тәртипсезлек булырга тиеш дигән сүз түгел. Алга таба бернечә киңәш биреп китәбез:

1. **Шелтәне йомшаклык белән белдер**

Әнәс бине Мәлик Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең беркайчан да әшәке һәм түбәнсетә торган сүзләр әйтмәвен риваять иткән (Бохари).

Безгә балаларның бер гөнаһсыз икәнлекләрен онытмаска кирәк. Аллаһы Тәгалә балаларга начар торышлары өчен җәза бирми, киресенчә, алар белән нинди мөнәсәбәттә булуыбыз өчен безне җаваплылыкка чакыра.

Безнең бурычыбыз – балаларга йомшаклык белән мәчеттәге тәртипләрне аңлату. Төрле яштәге бала да үзенә тавыш күтәреп, түбәнсетеп әйткән кешенең сүзенә колак салмый. Ә инде кайгыртып, йомшаклык белән үзенә эндәшкән кешенең сүзен игътибар белән тыңлар.

2. **Ярдәм кулыңны суз**

Бер атаның шук баласы артыннан йөгереп йөргәнен яки сабыен тынычландырырга теләгән ананы карап торганчы, аларга ярдәм итәргә тырышырга кирәк. Әгәр «сез намаз укыган вакытта мин сезнең улыгызны карап тора алам» яки «пакетыгызны күтәреп торыйм», дип ярдәмегезне белдерсәгез – ул сезгә, ин шә Аллаһ, садака булып язылыр.

3. **Искә төшерү**

Мәчетләрдә һәрвакытта да әти-әниләргә һәм балаларга мәчеттәге тәртипләр һәм үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен искә төшереп, әйтеп торырга кирәк.

4. **Уңайлы шартлар булдыру**

Мәчетләрдә ата-аналар һәм балаларга аерым урын бүленеп куелса хәерле. Монда әти-әниләре гыйбадәт кылганда яисә дини темаларга лекцияләр тыңлаган вакытта балалар үз уенчыклары белән уйный алырлар иде.

■ islam-today.ru

# «ЯШЕЛЧӘЛӘР ПАТШАСЫ»



Әлеге яшелчәдәге файдалы матдәләрне галимнәр кат-кат тикшергән. Мондагы ферментлар, җиңел үзләштерелә торган углеводлар, аксым, пектиннар, бик күп төрле витаминнарның барлыгы ачыклангач, кабакны «яшелчәләр патшасы» дигәннәр.

## Коръәндә искә алынган яшелчә

Кабак турында Коръәни Кәримдә һәм Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең хәдисләрендә дә телгә алына. Алардан без әлеге яшелчәнең бик тә файдалы икәнлеген беләбез. Әйдәгез, моңа бергәләп инаныйк:

Коръәндә кабак Юныс галәйһиссәламнең тормышына бәйле телгә алына. Ул Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте белән балык карыныннан азат ителә. Өстендә киемнәре юк, хәтта тәнендә ит тә юк, бары тик сөякләре генә калган. Аллаһы Тәгалә аның өчен кабак агачын (йактыйн) үстерә һәм Юныс галәйһиссәлам аның яфраклары күләгәсенә урнаша.

Аллаһы Тәгалә Коръәндә әйтә:

**«Без аны берникадәр вакыт балык карынында торганнан соң, сырхау булган хәлдә корыга чыгарып ташладык, ягъни Аллаһы әмере белән балык Юнысны су читенә, корыга чыгарып куйды. Вә аның янында киң яфраклы агач үстердек, ул агач аңа кояштан күләгә булды һәм ул агач янына чебен, черки, кигәвен кебиләр килмәделәр, чөнки аның тәне җәрәхәтләнгән иде. Ул шул урында берничә көн торып, Аллаһының рәхмәте белән бик тиз сәламәтләнде».**

«Саффат / Сафта Торучылар», 37:145-146

## Кабак турында хәдисләр ни сөйли?

Шулай ук Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең күп кенә хәдисләрендә дә кабак турында искә алына. Әнәс бине Мәлик радыяллаһу ганһе: «Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм кабакны ярата иде», – дип әйткән (Тирмизи, Ибне Мәҗе, Ән-Нәсаи).

Хәкийм бине Җәбирдән риваять ителә, аның әтисе Җәбир бине Тарикъ Әл-Әхмәси әйткән: «Бервакыт мин Аллаһының Илчесе галәйһиссәлам янына кердем һәм анда кабак күреп, аннан: «Бу нәрсә?» – дип сорадым. Ул соравыма: «Без аның белән үз ризыгыбызны арттырабыз», – дип җавап кайтарды (Тирмизи, Әхмәд, Табәрани, Ән-Нәсаи).

Борынгы заманнардан ук кабак ашарга яраклы үсемлек буларак билгеле. Гарәпләр Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм заманында ук кабактан ризыклар әзерли торган булганнар. Моны без күп кенә хәдисләрдән дә ишетеп беләбез. Алда әйтеп үткәнебезчә, Мөхәммәд пәйгамбәр галәйһиссәлам үзе дә бу яшелчәне бик яраткан һәм кадерен белгән. Әнәс бине Мәлик радыяллаһу ганһедән китерелгән бер хәдистә әйтелә: «Бервакыт бер сәхабә Мөхәммәд пәйгамбәр галәйһиссәламне үзе әзерләгән ризыктан авыз итәргә дип кунакка чакырды. Пәйгамбәр галәйһиссәлам белән мин дә бардым. Теге кеше Аллаһының Илчесе галәйһиссәламгә ипи, телемләп кабак һәм киптерелгән ит кисәкләре салынган аш бирде. Мин Пәйгамбәр галәйһиссәлам үз тәлинкәсенең кырыеннан кабак телемнәрен алганын күрдем. Шул көннән үзем дә кабакны яраттым».

Хәдисләрдән билгеле булганча, сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм Гайшә радыяллаһу ганһәгә ризык әзерләгән вакытта, әлеге яшелчәнең тынычландыру үзлегенә ия булуын искәртеп, кабак кулланырга киңәш иткән. Пәйгамбәребез галәйһиссәлам болай дип әйтә торган булган: «Йә Гайшә, ризык әзерләгән вакытта син аңа күбрәк кабак сал, чөнки ул сагышлы йөрәкне ныгыта!»

Шулай ук тагын бер хәдистә Әбү Талут радыяллаһу ганһе әйткән: «Мин Әнәс бине Мәлик янына кердем. Ул: «Аллаһының Илчесе яратып ашаганга күрә, син миңа бик кадерле ризык», – дип әйтә-әйтә кабак ашый иде».

## Мөселман табиблары кабакның файдасы хакында

Күренекле табиб Ибне Сина да кабакның файдалы үзлекләрен билгеләп киткән. Кабак төнәтмәсен ютәлдән дәваланганда кулланырга киңәш иткән. Аның фикеренчә, кабактан яңа гына чыгартылган сокны гөлчәчәк (роза) мае белән кушсаң, ул колак авыртуларын баса һәм тамак авыртуларыннан да файдалы икән. Көнчыгышның күп кенә табиблары фикере буенча, кабакны нинди рәвештә кулланссаң да, ул артык ярсучанлыкны баса.

Мөхәммәд Хөсәйн Шерази исә кабак организмны ныгыта, эчәкләрне йомшарта, сары авыруын һәм көчле бизгәк авыруыннан ярдәм итә дип билгеләп үтә.

## Кабакның кеше сәламәтлеге өчен файдасы

Кабакның файдалы үзлекләре бихисап, хәтта аларны санап бетерү мөмкин түгел. Ул үзенә бик күп микроэлементларны һәм витаминнарны җыйган. Үзенең файдалы матдәләргә бай булуы белән кабак башка төр яшелчәләрне уздыра. Аның составында каротин, шикәр, С, В1, В2, В5, В6, Е, РР витаминнары һәм дә сирәк очрый торган Т витамины бар. Ә ул организмда матдәләр алмашын яхшырта, кан әйләнешен тизләтә. Шулай ук кабакта канның оешуы өчен мөһим булган К витамины, майлар, аксым, углеводлар, целлюлоза, пектин матдәләре, минераллар һәм дә калий, кальций, тимер бар.

Кабакта кишергә караганда өч мәртәбә, ә сыер бавырына караганда биш тапкырга артыграк каротин бар. Шул сәбәпле күз күреме начарланган кешеләргә офтальмологлар кабак яки кабак согын кулланырга киңәш итәләр.

Составында тимер булган яшелчәләр арасында кабакны беренчелектә дип әйтә алабыз. Шуңа күрә кабакны анемия (азканлылык) белән интегүчеләр дә куллансалар хәерле.

Медицина тәҗрибәсеннән күренгәнчә, кабак куллану простата бизе яман шеше булуны киметә, буыннар ялкынсынуыннан саклый, җыерчыкларны бетерә, бөерләрнең эшчәнлеген тәртипкә сала. Һиндстанда исә кабакны туберкулёздан дәвалану өчен кулланалар. Ул шулай ук халык медицинасында да киң кулланыла: тән өшегәндә, тире кызару күзәтелгәндә, кабакны уып, җәрәхәтле урынга куярга мөмкин.

Кабак диетасы йөрәк-буыннар авыруларыннан, матдәләр алмашыну бозылганда ярдәм итә, эчәкләрнең эшчәнлеген яхшырта. Кабак согы нерв системасын тынычландыра, йокыга уңай йогынты ясый, сусауны баса һәм бавыр, бөерләр авыруларыннан да кулланырга киңәш ителә.

Кабак диетик ризык булып тора. Бавыр, үт куыгы белән бәйле авырулар, гастрит булган вакытта бигрәк тә файдалы. Яңа гына чыгартылган кабак согы бәвел юллары ялкынсынуыннан, хроник эч катудан, нервларның бозылуыннан кулланыла. Кабактан әзерләнгән ботка исә ябыгырга теләүчеләр өчен бик тә файдалы, чөнки ул матдәләр алмашын тәртипкә сала һәм оранизмнан шлакларны чыгара.

Әгәр сез йокысызлыктан интегәсез икән, йоклар алдыннан кабак согы яки бал кушылган кабак төнәтмәсе эчеп куйсагыз хәерле. Кабактан әзерләнгән төнәтмә сусауны баса, югары температураны төшерә.

Кабакның үзе генә түгел, ә төшләре дә туклыклы һәм файдалы. Кабак төшенең составында 52% кадәр майлар һәм 28% аксым бар. Ауропаның күп кенә илләрендә кабак маен төрле яшелчә салатлары әзерләгәндә кулланалар. Шулай ук кабак төшләре цинкка бик бай. Организмга цинк җитмәгәндә, чәч кавыклаганда, бетчәләр чыкканда кабак төшләрен ашарга кирәк. Шулай ук төелгән кабак төшләрен бал белән кушып куллану – бабасырга каршы борынгыдан килгән чараларның берсе.

Шул чаклы файдалы яшелчә тагын тәмле дә була аламы дип уйлап куясың кайчакларда. Ләкин шуңа да карамастан, бу чыннан да шулай һәм кабак моның ачык мисалы.

■ **Сәхифәне Лилия Хәләфетдинова әзерләде**

## Имам әдәпләре

- Имам булып намазның фарызларын һәм сөннәтләрен яхшы белүче кеше генә тора ала.
- Намазны боза торган шартларны белергә.
- Үзең артыннан гыйлемле кешене басты-рырга.
- Намаз алдыннан әдәпле генә, кул ишарәсе белән сафларны тигезләргә сорарга.
- Озын сүрәләр укымаска, чөнки бу җәмәгатькә кыенлык китерергә мөмкин.
- Тәсбихләрне озакка сузмаска.
- Әмма шул ук вакытта намазларны аларның дәрәҗәсен киметерлек итеп кыскартмаска.
- Намазны укыганда мәчеттәге авыру, хәлсез, өлкән кешеләрнең санын истә тотарга.
- Рөкүгъ һәм сәҗдә вакытында, җәмәгать намазны хошугълык белән башкарсын өчен, тәсбихләрне әкрен әйтергә. «Фәтиха» сүрәсен укыр алдыннан һәм укыгач, шулай ук өстәмә сүрә укы-лгач, берникадәр вакыт дәшми торырга (тынлык сакларга). Әгәр кемнеңдер намазга кушылырга ашыгуын ишетсәгез, рөкүгъ вакытында аны бераз көтеп торырга кирәк (әлбәттә, әгәр бу җәмәгатькә кыенлык китермәсә). Әгәр намазның вакыты чы-гачак дигән курку булмаса, күршеләрнең намазга кереп җитүен бераз көтеп торырга. Беренче һәм икенче «сәлам» арасында, алар аерылып торсын өчен, бераз гына туктап торырга.Намаздан соң Аллаһы Тәгаләә биргән нигъмәтләр турында уйла-ныып, Аңа рәхмәтләрне җиткерү.

## Җомга намазы әдәпләре

- Намаз вакыты кергәнче, аңа әзерлек эшләрен тәмамларга.
- Вакыт керү белән үк, тәһарәтләнергә һәм иртәрәк мәчеткә китәргә.
- Госелләнергә.
- Чиста киемнәр кияргә.
- Тиешле күләмдә исле май кулланырга.
- Аз сөйләшергә.
- Һәрдаим Аллаһы Тәгаләне зекер итеп то-рырга.
- Имамга якынрак утырырга.
- Хөтбәне сөйләшмичә генә тыңларга.
- Намаз укыганнан соң гыйлем алырга юнәлергә.
- Йөргәндә салмак кына атларга.
- Адымнар зур булмасын.
- Башны бераз алга иярргә.
- Игелек эшләүчеләргә мактаулар әйтергә.
- Мәчеткә күркәм йөз белән керергә.
- Кешеләрнең сәламнәренә җавап бирергә.
- Хатыйб минбәргә менгәннән соң намазлар укымаска.
- Хатыйб җәмәгатькә сәлам биргәндә, аның сәламенә җавап кайтарырга.
- Сөйләшмәскә.
- Хөтбәне бар күңелне биреп тыңларга һәм нәсыйхәтләрне кабул итәргә.
- Хатыйб җәмәгатькә борылып хөтбә сөйли башлаганнан соң, як-якка борылмаска.
- Хатыйб минбәрдән төшмичә һәм мөәзин камәтне төшереп бетермичә, намаз укырга торма-ска.

## Ир-атның хатынына карата әдәпләре

- Хатынга яхшы мөнәсәбәттә булырга.
- Аның белән назлы итеп сөйләшергә.
- Аңа мәхәббәтеңне белдерергә.
- Икәүдән икәү генә калганда тыныч булырга.
- Кечкенә хаталарны күрмәскә тырышырга.
- Аның намусын һәм дәрәҗәсен сакларга.
- Хатын белән бәхәскә еш кермәскә.
- Аны тәэмин итәргә һәм саран булмаска.
- Аның гаиләсен ихтирам итәргә.
- Матур вәгъдәләр бирергә.
- Аны көнләргә.

## Хатынның иренә карата әдәпләре

- Ир алдында оялу хисен югалтмаска.
- Ир белән бәхәскә кермәскә.
- Аның теләкләрен үтәргә тырышырга.
- Ир сөйләгәндә дәшмәскә.
- Ир читтә булганда аның мал-мөлкәтен һәм дәрәҗәсен сакларга.
- Аның малын юк-барга сарыф итмәскә.
- Хушбуйлар сөртергә.
- Тышкы кыяфәтне тәртиптә тотарга.
- Чиста киемнәр кияргә.
- Канәгать булуын күрсәтергә.
- Мәрхәмәтле булырга.
- Бизәнү әйберләре тагып йөрергә.
- Ирнең гаиләсе һәм якыннарына карата их-тирамлы булырга.
- Эшләгән гамәлләре өчен иргә рәхмәтле бу-лырга.
- Икәүдән икәү генә калганда аңа яратуыңны белдерергә.
- Ирен күргәндә, шат булуын күрсәтергә.

## Шәкертнең остазына карата әдәпләре

- Беренче чиратта, һәрвакыт остазны сәламләргә.
- Остаз янында аз сөйләшергә.
- Остаз утырган җиреннән торганда, торып басырга.
- «Фәлән галим бөтенләй башкача әйтә», – кебек сүзләрне беркайчан да әйтмәскә.
- Янында утырган сабакташка сораулар бирмәскә.
- Остаз белән сөйләшкән вакытта көлмәскә.
- Остазның фикерләренә каршы килгән фикерләргә ишарә итмәскә.
- Остаз утырган җиреннән торганда, аның киеменә тотынмаска.
- Дәрестән соң өйгә кайтканда остазга сора-улар бирмәскә.
- Дәрес вакытында остаз арыса, дәресне дәвам иттерүне сорамаска.

## Коръән өйрәтүченең әдәпләре

- Тәкъва кыяфәт белән утырырга.
- Шәкертләрнең укуын тыңларга.
- Аңлар өчен, сөйләшмәскә.
- Аллаһы Тәгаләнең ризалыгын өмет итәргә.
- Охшаш хәрефләрнең әйтелешенә игътибар итәргә.
- Коръән укыганда тукталыш урыннарын әйтергә.
- Укуны туктатканда, укуны дәвам иттерү-нең тәртипләрен аңлатырга.
- Саннарны өйрәтергә.
- Тәҗвид һәм авазларның дөрес әйтелешен өйрәтергә.
- Хәтем чыгуның савабын аңлатырга һәм хәтем чыкканнан соң эшләнергә тиешле гамәлләрнең тәртибен аңлатырга.
- Күптән түгел генә Коръән укый башлаучы-ларны аңлап, йомшак мөгамәләдә булырга.
- Шәкерт дәрескә килмәгәндә, һәрвакыт дәерс калдыруының сәбәбен сорарга.
- Бу шәкерт дәрескә килгәч, аны укырга өндәргә.
- Аз сөйләшергә.
- Шәкертләргә намазда укыла торган сүрә-аятьләрне яки алар имам булгач укырга кирәк бу-лачак сүрәләрне ятлатырга.

## Коръәнне өйрәнүченең әдәпләре

- Остаз каршында тыйнак кына утырырга.
- Остаз сөйләгәннәрне аңлар өчен, бик игъ-тибарлы булырга.
- Башны бераз аска иярргә.
- Коръәнне укый башлар алдыннан остаздан рөхсәт сорарга.
- Шуннан соң «Әгузү-бисмилләһ»не әйтергә.
- Укуны тәмамлаганнан соң, дога кылырга.

## Кечкенә балаларны укытучы мөгаллимнәрнең әдәпләре

- Беренче чиратта тышкы кыяфәтне тәртипкә китерергә, чөнки балаларның бар игъти-бары шуңа юнәлтелгән була. Мөгаллим нәрсәне матур дип санаса, балалар да шуны матур санар. Мөгаллим нәрсәне әшәке дип тапса, балалар өчен дә шул әшәке булыр.
- Утырганда сөйләүдән туктарга кирәк, ягъ-ни кирәк вакытта гына сөйләргә.
- Җитди кыяфәт сакларга.
- Тәрбия эшендәге мөһим мәсьәләләрне җитди һәм хөрмәт белән башкарырга.
- Укучыларга сукмаска һәм аларны җәзаламаска.
- Мәгънәсез әңгәмәләр кормаска, юкса, уку-чы үзенең хөрмәт итмәвен белдерергә мөмкин.
- Укучыларга бер-берсе белән сөйләшеп утырырга рөхсәт итмәскә.
- Укучылар янында беркем белән дә ша-яртмаска.
- Бүләкләр кабул итмәскә.
- Укучылар арасында бәхәсләр тууны бул-дырмаска.
- Начар сүз, гайбәтнең зарары турында сөйләргә.
- Ялган һәм гайбәтнең түбәнлеге турында сөйләргә.
- Истинҗә, юыну рәвешләрен, тәһарәт алу һәм намаз уку тәртипләрен өйрәтергә.

■ **Имам Әбү Хәмид Мөхәммәд Газалиның «Әдәпләр» китабыннан тәрҗемәләр**

# Сәламәтлек эликсиры

Аллаһы Тәгалә Коръәннең иң зур сүрәләренең берсе булган «Нәхел» / «Умарта кортлары» сүрәсенең 68-69 аятьләрендә: **«Раббың бал кортларына вәхи кылды: «Ий бал кортлары, тауларда, агачларда вә кешеләр тора торган җайларда үзегезгә оя ясагыз! Соңра һәр җимеш чәчәкләреннән бал ашагыз һәм җыегыз вә итагать итеп, Мин әмер кылган юлга керегез!» Бал кортлары кешеләр өчен эчләреннән төрле төстәге балларны чыгарып бирәләр, ул балларда ашар өчен тәме дә һәм кешеләр өчен шифасы да бар. Фикерле белгән кешеләр өчен бал кортларының эшендә зур гыйбрәт вә дөреслек бардыр»** – дип әйтә.

Әлеге аятьләрдән күренгәнчә, бу кечкенә гаҗәеп мавыктыргыч бөҗәкләрнең югары дәрәҗәдә оешкан, тырыш, гадел җәмгыять булып яшәүләре – бары тик Аллаһыдан. Бал корты туының беренче көнендә үз-үзен чистарта, ә аннан соң кәрәздәге күзәнәкләрне, туачак буынның личинкаларын тукландыра, җылыта. Башка кортлар алып кайткан чәчәк серкәсен, балны кәрәзләргә туплый, умарта эчен чисталыкта тота. Бал корты күрә, ис, тәм сизә, җылыны һәм дымлылыкны тоя, ишетә, көн вакытын төгәл билгели. Хәтта югары акыл иясе – кеше дә урманда адаша, ә бал корты умартадан биш-алты, җиде чакрым китсә дә, төгәл үз умартасына кайта ала. Ул бары тик бөҗәк кенә. Ә ул җитештергән бал, прополис, ана сөте, җыйган чәчәк серкәсе, перга, тәнгә таралучы корт агуы?! Боларның барысы да кешенең сәламәтлеген ныгыту, савыктыру өчен!

Бал кортларына кыйммәтле продукт җитештерү чыганагы итеп кенә карау дөрес булмас. Ник дигәндә, бу тырыш бөҗәкләр, чәчәктән-чәчәккә кунып, үсемлекләрне серкәләндерә, моның белән уңышның артуына һәм сыйфаты яхшыруга булышлык итә. Бал кортлары булмаса, авыл хуҗалыгы карабодай, көнбагыш, җиләк-җимешләрдән меңәрләгән тонна уңышны кимрәк алыр иде. Борынборын заманнарда ук балны Аллаһы тарафыннан җиргә кеше бәхетенә җибәрелгән бүләк дип санаганнар.

## Бал

Борынгы фикер ияләре балны озак яшәү мөмкинлеге бирә торган сәламәтлек эликсиры дип атаганнар. Ул электән үк бөтен халыкларда да киң кулланылган һәм уникаль медикаменттан саналган.

Бал хәзер дә кешеләрне күптөрле авырулардан дәвалый. Аның үсемлек һәм төрле үләннәр белән катнашмасы уңай нәтиҗә бирә: ашказаны-эчәк трактын нормальләштерә, аллергиягә, склерозга каршы көрәшә, тонусны күтәрә, ялкынсынуларны бетерә, матдәләр алмашын, тиренең туклануын яхшырта, организмны ныгыта һ.б. Балның составында антибиотиклар күп, шуңа күрә ул антибактериаль чара да булып тора.

## Куллану алымнары

Балның үзен генә дә, азыкка салып та кулланырга мөмкин. Физиотерапиядә балдан ванна, компресс ясыйлар, шәм, аэрозоль итеп файдаланалар. Миокардит, миокардиосклероз, гипертоник авырулар булганда, йөрәк ритмы бозылганда урман һәм дала, лаванда балы ашарга киңәш ителә. Бал ашаганнан соң, андагы глюкоза белән фруктоза бик тиз канга күчә һәм йөрәк мускулын һәм башка тукымаларны тукландыра.

Салкын тигәндә, бронхит, туберкулез белән чирләгәндә, балның сөт, май, алоэ белән катнашмасы аеруча ярдәм итә.

Гинекологик авырулар булганда хатын-кызларга юкә, урман һәм бөтнек балы ярдәмгә килер. Белгечләр фикеренчә, балны озак вакыт, һичьюгы 1-2 ай буе куллану йөрәк мускулының кысылган тамырларын киңәйтә, кан йөрешен һәм кислород килүен яхшырта, кан басымын нормальләштерә.

Әмма дә ләкин балны күп ашарга (бигрәк тә кайнар чәй белән) ярамый, чөнки бу нерв системасын ярсыта, тирләүне көчәйтә. Тәүлеккә 50-70 г арттырмаска кирәк.

Халык медицинасында йөрәккан тамырлары авыруларын дәвалауда балны дару үләннәре белән тәкъдим итәләр. Мәсәлән, бал белән балан бик тә файдалы. Аяктагы кан тамырлары авырулары – варикоз, йөрәк-ишемия авыруыннан бал белән сарымсак тәкъдим ителә.

## Балның файдалы үзенчәлекләре

Әйткәнәбезчә, бал – авырулардан дәвалану, тән һәм организм өчен табигый шифалы дару. Аллаһы Тәгалә балга шифаны Үзе салган. Ул экологик яктан иң чиста азык. Балның кайбер файдалы үзенчәлекләрен санап үтик:



- Көнгә бер бал кашыгы бал куллану организмны грипптан һәм салкын тиюдән саклый.
- Җылы суга болгатылган балны эчү кешедә стресс һәм арыганлык халәтен киметә.
- Бал хәтерне һәм күрү сәләтен яхшырта.
- Бал организмдагы буыннарны ныгыта.
- Бал диабетиклар өчен куркынычсыз.

## Умарта кортларының һәм кортчылык продуктларының файдасы

Кортчылык продуктлары кеше тарафыннан, беренче чиратта, сәламәтлек өчен файдалы һәм туклыклы булганга, шулай ук бизәнү сәнгатендә киң кулланыла.

Бал кортлары туклыклы һәм шифалы бал бирәләр. Балны йөрәккан тамырлары, үпкә, күз авырулары, шулай ук яраларны дәвалау өчен кулланалар. Ул бавыр, бөер, ашказаны эшчәнлеген яхшырта.

Шулай ук бал конфет, прәннек, салат, бәлеш, торт, куе ширбәт, төнәтмә кебек ризыклар составында көндәлек һәм бәйрәм өстәлендә килә. Бу – балның шифалы һәм диетик өстенлекләрен ассызыклый.

Чәчәк серкәсен, ягъни «перга»ны, медицинада балаларда азканлылыкны дәвалау өчен кулланалар. Ул кандагы эритроцитларны һәм гемоглабинны күтәрә.

Ана корт сөте туклыклы һәм кыйммәтле матдә. Ул майларга, витаминнарга һәм аксымнарга бай. Организмда матдәләр алмашын яхшырта. Прополисны суык тигәндә һәм авыртуны басуда кулланалар. Бал кортының агуы, кеше организмында иммунитетны ныгыта, ревматизмны дәвалый.

Хәзерге медицина өлкәсендә махсус дәвалау системасы барлыкка килде, соңгы вакытта кортлардан чактыру (апитерапия) киң кулланыла. Апитерапия һәм бал кортлары белән дәвалану Ислам динендә рөхсәт ителә, хуплана. Ул астма, язва кебек кан әйләнеше һәм аш кайнату системалары авыруларының күбесен дәвалый, иммунитетны ныгыта. Шулай ук аның нурланышка (радиациягә), микробларга каршы тәэсире бар; депрессия, физик һәм психик киеренкелек, атеросклероз, энцефалит, симерү һәм организм эштән чыгу очракларында да файдалы. Склероз, ДЦП кебек авыруларны дәвалауда да уңай нәтиҗәләр бирә.

Әгәр дә бал кортының агуы кеше организмына әләгә икән, аллергия булмаган кешегә ул куркыныч түгел. Тик йөкле хатын-кызларга, яман шеш авыруы белән авыручыларга, шикәр диабеты белән авыруган кешеләргә мондый сеансларга барырга ярамый.

Язмабызны Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вә сәләмнең хәдисе белән тәмамлыйсы килә. Габдулла бине Мәсгудтән китерелә, Пәйгамбәребез галәйһиссәлам болай дип әйткән: «Бал – барлык тән авыруларыннан, ә Коръән – барлык акыл авыруларыннан дәва. Шуңа да мин сезгә тулысынча дәвалану өчен аларның икесен дә: Коръән һәм балны да кулланырга киңәш итәм».




## «Хозур» нәшрият йорты М. Сөләйманиның дүрт томлы «Ислам тарихы» китабын нәшер итте

«Ислам тарихы» – XX йөз башында татар телендә нәшер ителгән бик кыйммәтле хезмәт булып тора. Ул гарәп кабиләләренең һәм кавемнәренең кыскача тарихын тасвирлаудан башланып, үз эченә Мөхәммәд Мостафа саллаллаһу галәйһи вә сәлләмнең нәсел-нәсәбе, тормышы, Ислам диненең таралуы, тугрылыклы хәлифәләр чорын ала.

Хезмәтнең авторы М. Сөләймани гарәп һәм төрек телләрендә иҗат ителгән һәм дөньякүләм билгеле булган тарихи чыганакларга таяна, аларда тасвирланган вакыйгаларны чагыштырып, үз әсәрендә бары тик тикшерелгән һәм тәгаен билгеле булган мәгълүматларны туплый.

Бер гасырдан артык вакыт узгач, М. Сөләйманиның «Ислам тарихы» гарәп имлясыннан күчерелеп, яңа киң катлам укучыларга тәкъдим ителә.

- **Кибетләрнең адреслары:**
  - Тукай урамы, 36 йорт;
  - Газовая урамы, 14 йорт.
- **Белешмәләр өчен телефон:**
  +7 (903) 388-86-33.




**«Дин вә мәгыйшәт» газетасына 2019 елның икенче яртысына язылу башланды**

- Ярты елга язылу бәясе: 132 сум
- Газета айга бер тапкыр чыга
- Язылу индексы: П4333

Түбәндәге сайтларда да язылу мөмкин:
podpiska.pochta.ru һәм uslugi.tatarstan.ru сайтының «Подписка» бүлегендә.

دين ومعيشت
дин вә мәгыйшәт

Белешмәләр өчен телефон: 598 09 42

## КАЗАН ӨЧЕН ИЮЛЬ АЕНА НАМАЗ ВАКЫТЛАРЫ

| Көн | Иртәнге намаз: Сәхәр тәмам | Иртәнге намаз: Мәчетләрдә укыла | Кояш чыга | Өйлә намазы | Икенде намазы | Ахшам намазы | Ястү намазы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 01.07.2018 | 01:03 | 01:33 | 03:03 | 12:00 | 17:34 | 20:31 | 22:01 |
| 02.07.2018 | 01:03 | 01:33 | 03:03 | 12:00 | 17:34 | 20:30 | 22:00 |
| 03.07.2018 | 01:04 | 01:34 | 03:04 | 12:00 | 17:34 | 20:30 | 22:00 |
| 04.07.2018 | 01:05 | 01:35 | 03:05 | 12:00 | 17:33 | 20:29 | 21:59 |
| 05.07.2018 | 01:06 | 01:36 | 03:06 | 12:00 | 17:33 | 20:28 | 21:58 |
| 06.07.2018 | 01:07 | 01:37 | 03:07 | 12:00 | 17:33 | 20:27 | 21:57 |
| 07.07.2018 | 01:08 | 01:38 | 03:08 | 12:00 | 17:33 | 20:27 | 21:57 |
| 08.07.2018 | 01:10 | 01:40 | 03:10 | 12:00 | 17:32 | 20:26 | 21:56 |
| 09.07.2018 | 01:11 | 01:41 | 03:11 | 12:00 | 17:32 | 20:25 | 21:55 |
| 10.07.2018 | 01:12 | 01:42 | 03:12 | 12:00 | 17:31 | 20:24 | 21:54 |
| 11.07.2018 | 01:13 | 01:43 | 03:13 | 12:00 | 17:31 | 20:23 | 21:53 |
| 12.07.2018 | 01:15 | 01:45 | 03:15 | 12:00 | 17:30 | 20:22 | 21:52 |
| 13.07.2018 | 01:16 | 01:46 | 03:16 | 12:00 | 17:30 | 20:21 | 21:51 |
| 14.07.2018 | 01:17 | 01:47 | 03:17 | 12:00 | 17:29 | 20:19 | 21:49 |
| 15.07.2018 | 01:19 | 01:49 | 03:19 | 12:00 | 17:29 | 20:18 | 21:48 |
| 16.07.2018 | 01:20 | 01:50 | 03:20 | 12:00 | 17:28 | 20:17 | 21:47 |
| 17.07.2018 | 01:22 | 01:52 | 03:22 | 12:00 | 17:27 | 20:16 | 21:46 |
| 18.07.2018 | 01:23 | 01:53 | 03:23 | 12:00 | 17:27 | 20:14 | 21:44 |
| 19.07.2018 | 01:25 | 01:55 | 03:25 | 12:00 | 17:26 | 20:13 | 21:43 |
| 20.07.2018 | 01:26 | 01:56 | 03:26 | 12:00 | 17:25 | 20:11 | 21:41 |
| 21.07.2018 | 01:28 | 01:58 | 03:28 | 12:00 | 17:24 | 20:10 | 21:40 |
| 22.07.2018 | 01:30 | 02:00 | 03:30 | 12:00 | 17:24 | 20:08 | 21:38 |
| 23.07.2018 | 01:31 | 02:01 | 03:31 | 12:00 | 17:23 | 20:06 | 21:36 |
| 24.07.2018 | 01:33 | 02:03 | 03:33 | 12:00 | 17:22 | 20:05 | 21:35 |
| 25.07.2018 | 01:35 | 02:05 | 03:35 | 12:00 | 17:21 | 20:03 | 21:33 |
| 26.07.2018 | 01:37 | 02:07 | 03:37 | 12:00 | 17:20 | 20:01 | 21:31 |
| 27.07.2018 | 01:38 | 02:08 | 03:38 | 12:00 | 17:19 | 20:00 | 21:30 |
| 28.07.2018 | 01:40 | 02:10 | 03:40 | 12:00 | 17:18 | 19:58 | 21:28 |
| 29.07.2018 | 01:42 | 02:12 | 03:42 | 12:00 | 17:17 | 19:56 | 21:26 |
| 30.07.2018 | 01:44 | 02:14 | 03:44 | 12:00 | 17:16 | 19:54 | 21:24 |
| 31.07.2018 | 01:46 | 02:16 | 03:46 | 12:00 | 17:14 | 19:52 | 21:22 |

**ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ**
*Июнь саны, №6 (287)*

Баш мөхәррир: **Нәширбанов И.К.**
Мөхәррир: **Маннанова Р. Р.**
Дизайнер: **Даутов Р. А.**
Яңартылган логотип авторы: **Димасов Э. И.**
Биткә салучы: **Сәйфетдияров Р. Г.**
**Редакциянең һәм нәшер итүченең адресы:**
420111, Казан шәһәре, Лобачевский ур., 6 нчы йорт
**Электрон адресы:** shura@huzur.ru
**Телефон:** +7 (843) 598-09-42

**РЕДАКЦИЯ СОВЕТЫ:**
Татарстан мөфтие, Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте рәисе
**Камил СӘМИГУЛЛИН;**
«Хозур» нәшрият йорты директоры
**Ришат ХӘМИДУЛЛИН**;
ТР МДНнең дәгъвәт бүлеге җитәкчесе
**Булат МӨБӘРӘКОВ;**
Татарстанның баш казые
**Җәлил ФАЗЛЫЕВ;**
ТР МДНнең Голәмәләр шурасы әгъзасы
**Габдулла ӘДҺӘМОВ**

**Гамәлгә куючы:** Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте (420024, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Габдулла Тукай урамы, 38).
**Нәшир:** «Хозур» нәшрият йорты (420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6 нчы йорт)

Газета Татарстан Республикасы матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 нчы февралендә 240 нчы номер белән теркәлгән.
Материалларны күчереп бастырганда кайдан алынганлыгын, авторларын күрсәтү мәҗбүри.
Газета «Татмедиа» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды (420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2)
Тираж: 5 мең данә Заказ №2750
Газетага ярты елга язылу бәясе – 132 сум. Индексы – П4333. Казан шәһәренең мәчетләрендә 25 нче июнендә таратыла.
График буенча бу санга 24 нче июнь көнне 21.00 сәгатьтә кул куелырга тиеш иде. Кул куелды: 21.00 сәгатьтә.